Татарстан Фәннәр Академиясе
Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих Институты

**С.Х.Алишев**

# КАЗАН ХАНЛЫГЫ ЧОРЫНДАГЫ ТАТАРЧА ЧЫГАНАКЛАР

Казан 2002

УДК 947.1(9)
ББК 63,3 (Тат)
А 50

Мөхәррире **Р.Г.Әмирханов**

**С.Х.Алишев.** Казан ханлыгы чорындагы татарча чыганаклар**.** Казань: Институт истории АН РТ, 2002. – 72 с.

Бу китап Казан ханлыгы чорында булган төп чыганакларны бергә туплап, комплекслы рәвештә күзаллау өчен, карап чыгуны максат итеп куя. Монда дәүләти актлар- хан ярлыклары, тормышта булган төрле вакыйгалар — сәяси һәм иҗтимагый хәлләр турында аерым кешеләрнең язмалары урнаштырыла. Кабер ташындагы эпитафияләр, шәҗәрәләр, халык авыз иҗаты һәм матур әдәбият әсәрләре халкыбыз тарихын өйрәнүдә зур урын тотып торалар. Алар турында моңа кадәр бергә туплап язу булмады бугай. Китап тарихчыларга, филологларга һәм барлык кызыксынучыларга файдалы булыр дип өмет итәбез.

# 1. Документаль чыганаклар

## *Казан ханнары ярлыклары*

Татар халкы тарихы буенча урыс телендә күп язылды, татар телендә исә бик аз. Татарча чыганаклар турында язмаларны үзебезнең телебездә бирү мәслихәт булыр. Безнең татарча документ-чыганаклар да русча байтак басылдылар. Шуның өчен аларның элек урысча басылганнарын да яңадан татарчага күчереп калдыру кирәк дип уйлыйм.

XV-XVI гасырның беренче яртысына караган татарча тарихи чыганаклар күп түгел. Шулай да аларның җыелмасын карап тикшерү зарур. Болай эшләгәндә татар халкының үз дәүләте булган чор тарихына аларның нинди ачыклык керткәне хәл ителер иде. Ләкин мондый чыганаклар бик аз күләмдә сакланып калган. Казан ханлыгы чорындагы татарча чыганакларны без түбәндәге төрләргә бүлеп тикшерәбез: документаль чыганаклар, кабер ташы язмалары, шәҗәрәләр, халык авыз иҗаты үрнәкләре, матур әдәбият әсәрләре.

Күренә ки, биредә без археология чыганакларын алмадык, чөнки алар махсус рәвештә тикшерелә.

Документаль чыганаклар дигәч, без беренче чиратта Казан ханнарының төрле шәхесләргә биргән ярлыкларын күздә тотабыз.

Ярлык — борынгы төрки сүз «ярлек»тән алынган һәм «боерык» дигәнне аңлата. Соңрак Алтын Урда ханнарының кемне дә булса салымнардан азат итүче, ташламалы боерыклары да шулай дип аталган. Алар, Алтын Урда ханнары нәселеннән чыккан ханнар белән бергә Казан дәүләтенә дә килеп кергән. Безгә кадәр килеп җиткән ярлыкларның беренчесе - Ибраһим хан ярлыгы. Аңа Казан дәүләт университеты аспиранты Рафаэль Степанов Мәскәүдәге борынгы актлар саклана торган Дәүләт архивында эшләгәндә юлыга. (1) Ләкин бу документ төп нөсхә түгел, ә күчермә генә икән. Аның тарихы болай була. 1685 елда Казан өязе Тыңламас авылы кешесе Котлымөхәммәт Котлыгошев үзенең фамилиясен тархан дип санауны, шул дәрәҗәгә күтәрүне сорап патша исеменә гариза күндерә. Чөнки минем бабаларым Казан ханнары чорында ук тархан булганнар, дип яза ул. Шуны исбатлау өчен гаризасы белән бергә ярлыкның Артык Иманаев тарафыннан башкарылган русча күчермәсен властьларга тапшыра. Төп нөсхәсе югалган яки моңа кадәр табылмаган дип фараз ителә.

М.Госманов, Ш.Мөхәммәдъяров, Р.Степанов «Казан утлары» журналының 1965 елгы 8 нче санында «Яңа ярлык» дип аталган мәкалә

урнаштырдылар. (2) Бу мәкаләдә Ибраһим хан ярлыгының хәзерге татар теленә тәрҗемәсе дә китерелгән. Әнә шуннан алып, төзәтмәләр керткәч, текст болай яңгырый:

«Ибраһим хан

Суюргал сүзем. Ходайның ризалыгы, Алла илчесе Мөхәммәтнең Шәфәгате (яклавы) өчен бу үксез угыл һәм тол хатынны азат тархан булсын дидек. Бу азат җибәрелгән кешеләрнең исеме: Гөл-Бостан хатын һәм аның улы шаһ нәселе— Җанәкә солтан нәселе Мөхәммәт Газиз хан. Шундый исемле кешеләр азат ителде. Тагын аларның Хушкилде исемле чуралары да (хезмәтчесе дә) бергә азат булсын дидек, һәм тагын Мөхәммәт Гали Мөхәммәт Газизнең элекке хуҗасы бүләк итеп биргән бу ике тамга урманын ил агалары белән бергә ирәктә (Кремльдә) аларга яңадан бүләк иттек. Болардан башка билгесез бер нинди кеше аларның урманнарына йөрмәсеннәр; иген игеп, сабан сөрсә хәрҗ- анбар алмасыннар; аларга көч белән кунак төшермәсеннәр; тарханнар һәм илчеләр алардан олау һәм менү атлары алмасыннар; шулай ук теләсә кайсы яктан да җәбер итмәсеннәр дип (элек) Хәйдәр Гали солтан тарафыннан азат ителгән Гөл Бостан хатынга, аның улы шаһ нәселе- Җанәкә солтан нәселе Мөхәммәт Гали Газиз ханга, шулай ук Хушкилде исемле хезмәткәренә алар тота торган бу дәрәҗәле ярлык бирелде. Тарих сигез йөздә рамазан аеның берендә язылды.

Хаҗи Корбан-хафиз язды»

Ярлыкның теле һәм термин- атамалары турында матбугатта бәхәс тә булып алды. Әхмәт Булатов «Казан утлары»ның 1966 елгы 8 нче санында «Ибраһим хан ярлыгын укуга карата» дигән мәкалә бастырды. (3) Анда ул «чура» термины кол дигәнне аңлата, ә тәрҗемәдә «хезмәтче» итеп биргәнсез дип дәгъва кыла. Аңа каршы шул ук журналның 1967 ел 6 нчы санында М. Госманов бастырган «Тагын Ибраһим хан ярлыгы турында» дигән мәкаләдә «чура» сүзе төрле вакытта төрле мәгънәгә ия булган, кайбер мисаллар аны «кол» дип кенә аңларга ирек бирми» дигән җавап бирелә. (4) Шул ук фикерләр авторның «Татарские исторические источники. XVII- XVIII вв.» дигән китабында да кабатландылар. (5)

Ярлыкның транскрипциясе һәм русча тәрҗемәсе күренекле тел галиме Ф. С.Фәсиев тарафыннан ясалып, 1982 елда чыккан «Старотатарская деловая письменность XVIII века» дигән китабында урын алды. (6) Транскрипция мәсьәләсен тел галимнәренә калдырып, мин биредә бер

генә нәрсә әйтмәкче булам. Бу урысча тәрҗемә бик вакытлы һәм кирәк иде. Соңгы урысча вариант С. Х. Алишев төзегән «Источники по истории Татарстана» (Казань, 1993) дигән чыганаклар җыентыгында дөнья күрде, ул әнә шул Ф.С.Фәсиев хезмәтеннән алып урнаштырылган. (7)

Инде ярлыкның эчтәлегенә кагылышлы берничә сүз. Ярлык Гөл Бостан хатын һәм аның улы Мөхәммәт Газизне чурасы Хушкилде белән бергә салымнардан азат итү өчен, аларга җәбер-золым күрсәтмәскә боерып суюргал хокукы бирү турында язылган. Урман, кырлары өчен салым түләтмәскә, килгән -киткән чиновникларга олау һәм атлану атлары куймаска диелгән. Ярлык кремльдә (Ирәктә) бирелгән. Ләкин кайдагы кремльдә —Казандагымы, әллә башка бер җирдә кремль булганмы? Без моны белмибез, ләкин ирәктәнең башка бер җирдә булуы да бик мөмкин. Тексттан күренүенчә Ибраһим хан аңа кадәр гамәлдә булган суюргал ярлыкны, Хәйдәр Гали солтан ярлыгын беркетеп, яңартып биргән. Ләкин Казанда Хәйдәр Гали хан яки солтан булуы билгесез. Димәк, Хәйдәр Гали башка бер җирдә хәкимлек иткән. Тарихта мәгълум, XIV гасырда Болгар җире төрле әмирлекләргә бүленә: Булгар, Казан, Җүкәтау, Кирмән һәм башкалар. Хәйдәр Гали шундый әмирләрнең берсе, Татарстанның көньяк-көнчыгыш өлешендә урнашканының әмире-солтаны булган, күрәсең. Ярлыкның күчермәсе Татарстанның Тыңламас авылы кешесе Котлымөхәммәт Котлыгошевта саклануы шушы хакта сөйли булса кирәк.

Ярлык үзе һиҗри белән 800 нче елда язылган. Юлиан календаре буенча ул 1398 елга туры килә. Ә Ибраһим хан Казанда 1467-1479 елларда хан булып тора. Күчермәне эшләүче, бәлки, Хәйдәр Гали солтан тарафыннан бирелгән элекке ярлыкның датасын (вакытын-800=1398) үзгәртмичә калдыргандыр. Казанда 1395 нче елда Ентяк (Октяк) дигән кеше идарә итә, ләкин башка әмирлекләрдә хан яки солтан булып кемнең торуы безгә билгеле түгел.

Авыл исеме «Казан утлары» журналында «Тыңламас» дип бирелгән иде. М. Г. Усмановның 1979 елда чыккан «Жалованные акты Джучиева улуса.XIV—XVI вв.» дигән китабында ул Минзәлә районы «Танылмас» авылы дип әйтелгән. «Татарская АССР. Административно- территориальное деление» (Казань,1966) китабында исә «Тыңламас» авылы (Танылмас түгел) Актаныштан 9 чакрым ераклыкта урнашкан һәм Күзкәй авыл советына керүче татар авылы итеп күрсәтелгән. Минзәлә районында «Тыңламас» авылы да, «Танылмас» авылы да телгә алынмаган.

Ярлыкның әһәмияте турында кыскача шуны әйтергә кирәк: ул—

татар халкының феодализм дәверендәге хәл-әхвале, сәяси һәм социаль-экономик тормышы тарихына ачыклык кертә торган документ. Беренчедән, документ Казан ханлыгында XIV гасырда нык үскән феодал системаның яшәвен күрсәтә. Хан нәсел буенча тархан булып килгән феодал гаиләгә бүләк итеп урман һәм басу- кырлар бирә һәм салымнардан азат итә. Мондый кешеләр тархан дип аталганнар һәм үзләреннән бәйле кешеләрне тотканнар. Тарханлык хокукы киң таралган. Ләкин суюргал термины бары тик ханнар язган ике документта гына күренә. Алтын Урдадан килгән бу термин «суюргал системасы» дип бәяләрлек хәлдә булдымы икән дигән шик тудыра. Җир мөнәсәбәте буенча язылган язмаларда да, кабер ташы язмаларында да һәм халык авыз иҗаты мисалларында да бу термин очрамый.

Икенчедән, ул— Казан дәүләтенең XIV гасырдан ук сәяси тормыш ягыннан автономияле булуын, мөстәкыйллеген күрсәтүче язма документ. Болгар җирендә төрле әмирлекләр (солтанәтләр, урысча кенәзлекләр) яшәве билгеле. Шулардан берсе— XIV йөздә булган Хәйдәр Гали солтан хакимияте булганлыгы ачыкланды. Ярлыкның тел тарихын һ. б. тикшерүчеләр өчен дә әһәмияте зур.

Икенче ярлык — 1521- 1524 елларда Казан ханы булып торган, ә 1532-1551 еллардагы Кырым ханы атаклы Сәхибгәрәй хан ярлыгы. 1523 елда бирелгән бу ярлык (боерык) турында байтак язылды инде. Ләкин соңгы вакытта ул онытыла башлады кебек. Андый дәүләти актларны хәзерге вәзгыяттә бигрәк тә, һич тә күз уңаеннан төшереп калдырырга ярамый. Шуның өчен бу урында без аны өйрәнү тарихына да тукталырга булдык.

Ярлык археограф Сәет Габделмәннан улы Вахиди тарафыннан 1912 елда Мамадыш өязе Мамалай авылы крестьяне Рәхмәтулла Әхмәревта табылган. «Казан утлары» журналының 1965 елгы 8 нче санындагы «Яңа ярлык» дигән Ибраһим хан ярлыгы турындагы мәкаләдә авторлар М.Госманов, Ш.Мөхәммәдъяров, Р.Степанов, Сәет Вахиди 1912 елда бу Сәхибгәрәй хан ярлыгын юнәтә алмый, уку бәхетенә генә ирешә, ул аны бары тик егерменче елларда гына кулга төшерә, дип яздылар. Ләкин ярлык беренче мәртәбә үз, ягъни 1523 ел телендә Һади Атласи 1914 елда бастырып чыгарган «Казан ханлыгы» китабында урнаштырылган (9) Һ. Атласи ярлык текстын Сәет Вахидидән алып торган булырга тиеш, яисә аның кулдан күчермәсеннән файдалангандыр. Димәк, ярлыкны беренче дөньяга чыгаручы һәм аның үз телендәге текстын бастыручы Һ.Атласи булган дип әйтә алабыз.

Аннан соң ярлык белән мәшһүр тарихчы М.Худяков шөгелләнә. Үзенең «Очерки по истории Казанского ханства» дигән китабында М.Худяков С. Вахидигә югары бәя бирә, аның ярлыкка кагылышлы зур тикшерү эшләре алып баруын әйтә, документ эчтәлегенә туктала, аңардан өземтәләр китерә һәм зур әһәмияткә ия булуын күрсәтә. Билгеле булганча, М.Худяков китабы Казанда 1923 елда басылган, анда ярлыкның урнаштырылуы С.Вахидинең киң күңелле кеше булуы хакында сөйли. Ихтимал, ул болай уйлагандыр: ничек инде басылып чыгарга әзерләнгән Казан ханлыгы тарихы китапларына бу ярлыкның текстын бирмисең, әлбәттә, бирергә кирәк, халык белә торсын! Шундый ук фикер белән С.Вахиди ярлыкны үзе татарчага тәрҗемә итеп, күчермәсен Гәзиз Гөбәйдуллинга да тапшыра. Гәзиз «Татар тарихы» дигән китабының икенче басмасында: «Ярлыкның нөсхәсе бездә булмаганлыктан, Сәид Вахидов күчереп биргән рәвештә гыйләвә кылабыз», дип яза һәм шунда ук текстны тулысынча китерә. Ул Гали Рәхим һәм Гәзиз Гөбәйдуллин төзегән, 1925 елда бастырылып чыгарылган «Татар әдәбияты тарихы. Феодализм дәвере» дигән китапта да урын ала. Ниһаять Сәет Вахиди ярлык өстендә эшләвен тәмамлый һәм башта «Безнең юл» журналының 1925 елгы 3 нче санында (март ае) текстның үзен, хәзерге татарчасын һәм урысча тәрҗемәсен бастырып чыгара. Бу өч телдә чыгарылган беренче тулы басма була. Әле аңарчы ук автор «Вестник Научного общества Татароведения» журналының 1925 ел 1-2 саннарында (Январь—апрель) ярлык текстларын укучыга тәкъдим итә. (10) Инде аның тикшеренүләрен дөньяга чыгару вакыты җитә.

Казан университеты каршындагы «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте» белән «Татарны өйрәнү җәгыяте»нең 1925 ел 17 маенда бергә уздырылган утырышында Вахиди ярлык турында зур доклад ясый. Бу доклад язма рәвештә тагын да зуррак булып, әнә шул АИЭ җәмгыятенең «Хәбәрләре»ндә басылып чыга. (11) С.Вахидинең бу хезмәте Сәхибгәрәй хан ярлыгын ул вакытта мөмкин булган бөтен яктан тикшерүгә багышланган һәм галимне тирән фикерле тарихчы, төрки телләр белгече, киң кырлы археограф, ягъни чыганакларны эзләп табучы һәм аларны җентекле өйрәнү остасы итеп танытты. Бу хезмәткә соңрак әйләнеп кайтырбыз, хәзергә ярлыкның алга таба үткән юлын карыйк.

Ярлык тел галимнәре һәм тарихчылар тарафыннан өйрәнелә башлый. 1926 елда ук татарның Төркиягә киткән тарихчысы А. Баттал-Таймас «Казан йортында булынмыш тарихи бер документ —

Сәхибгәрәй хан ярлыгы» дигән мәкаләсен «Turkiyat Mecmuasi 11» дә урнаштыра. (12) Ул гарәп хоруфатында төрекчә язылган, мәкалә исемен без уңайлык өчен татарча бирдек. Автор ярлыкның Татарстан милли музеенда саклаучы текстына тәрҗемә ясаган.

Ярлык шулай ук, 1937 елгы «История Татарии в документах и материалах» дигән китапта да файдаланылган. Ул «Татарстан АССР тарихы»ның 1955 елгы урысча, 1960 елда чыккан татарча китабында да тиешле урынны алган һәм эчтәлеге, әһәмияте күрсәтелгән. Ә 1958 елда Чебоксарда басылган «Материалы по истории Чувашской АССР.Вып.1» китабында ярлыкны чуаш галимнәре дә үз искәрмәләре белән күчереп китерәләр.

1963 елда басылып чыккан «Борыңгы татар әдәбияты» китабында ярлыкның оригиналь тексты һәм хәзерге татар теленә тәрҗемәсе урнаштырылган.(13) Анда шундый искәрмә бирелгән: ярлыкның төп нөсхәсе Татарстанның Дәүләт музеенда саклана. Текст СССР Фәннәр Академиясе Казан филиалының фундаменталь көтепханәсендәге фотокопиядән алынды.

1967 елда Мәскәүдә басылып чыккан «Новое о прошлом нашей страны» дигән китапта Ш.Ф. Мөхәммәдъяров «Тарханный ярлык Казанского хана Сахиб—Гирея. 1523 г.» дип аталган мәкалә урнаштырды. (14) Анда автор тюрколог А.К.Боровков белән бергә ярлыкның яңа транскрипциясен, текстның үзен һәм урысча тәрҗемәсен бирә, ләкин хәзерге татар теленә тәрҗемәсе бирелми.

Шамил Фатыйхович фикеренчә моңа кадәр эшләнгән транскрипцияләр —укылышлар канәгатьләнерлек түгел. А.Баттал да, «Борынгы татар әдәбияты» авторлары да һәм башкалар да С. Вахидигә ияреп, аның артыннан барып, зур гына ялгышлар җибәргәннәр. Имеш, С. Вахиди ярлыкның үзен түгел, ә күчермәсенең фотокопиясеннән генә файдаланган һәм шуннан тәрҗемә иткән. Бу копия СССР Фәннәр академиясендәге Азия халыклары Институтының Ленинград бүлегендә саклана, ә А. Баттал кылган тәрҗемә Татарстан АССР Дәүләт музеендагы ярлык копиясеннән алып ясалган,дип яза. Ярлыкның үзе, төп нөсхәсе кайда соң, дигән сорауга автор болайрак җавап бирә: Ленинград Үзәк Дәүләт тарих архивының Сенат межәләү департаменты фондындагы башкортлар җире турындагы эш (дело) документлары ярлык язмышына ачыклык кертә. Җир турындагы бәхәсләр вакытында Сәхибгәрәй ярлыгы дәлил итеп китерелгән, шуннан урысча өзекләр XVII гасыр язмаларында чагылыш тапканнар икән. Ярлыкның төп нөсхәсе монда да юк. Гомумән, Шамил Фатыйховичка мондый чуалчык һәм аңлашылып бетми торган

язмалар хас түгел кебек иде.

Бездә ярлыклар белән махсус шөгелләнүче зур галим дип М.Г.Госмановны санарга кирәк. Аның 1979 елгы «Жалованные акты Джучиева улуса» китабында 61 ярлык, шул исәптән Казан ханнары Ибраһим һәм Сәхибгәрәйнеке дә, төрле яктан тикшерелгән. Ярлыкларның формаларын, эчтәлекләрен һ.б. якларын шәрехләүнең әһәмияте — үз чорындагы иҗтимагый тормышның, социаль- сәяси хәлнең ничек, ни дәрәҗәдә булганлыгын ачыклауда, дип яза автор.

М.Г.Госманов Татарстан Дәүләт музеенда Сәхибгәрәй хан 1523 елда язган ярлыкның төп нөсхәсе саклануын, ул 1912 елда Сәет Вахиди тарафыннан Мамадыш өязе Мамалай авылындагы (хәзер Татарстан республикасының Саба районы) Рәхмәтулла Әхмәров дигән кешедә табылуын раслый. шулай итеп, галим Ш.Ф.Мөхәммәдъров фикеренә кушылмый. Автор документны тарханлык ярлыгы дип атый һәм аның тасвирламасын бирә. Ярлыкның буе 76 см., иңе 17,7 см., кәгазе калын, ләкин бик таушалган, хәзерге вакытта ике пыяла арасында консервацияләнгән хәлдә саклана икән.

Ярлыкның урысча тәрҗемәсе соңгы вакытта С.Х.Алишев төзегән «Источники по истории Татарстана» дигән чыганаклар җыентыгында басылып чыккан иде. Ул С.Вахиди бастырган тексттан «Вестник научного общества Татароведения»дән алынды. С.Вахидине төрле төрки телләрне тирәнтен белүче галим буларак танып, монда без аның «Безнең юл» журналында гарәп графикасында бастырган текстыннан алып бирәбез.

«(Әс- Солтан) Әл- Газый Сәхиб-Гәрәй (сүзем)

Әмирләргә, хәкимнәргә, олы Сәетләргә, ислам казыйларына. Мөхтәрәм хуҗаларга, вәкаләт ияләренә, урыннардагы мәэмурләргә, илчеләргә, бакчачы һәм көймәчеләргә, урам башлыкларына, туткаул вә тамгачыларга, барча халыкка һәм Казан ханлыгының барча өлкәләренә вә барча мәмләкәтләргә (Анлар бәла вә афәтләрдән тыныч булгай иделәр) бу нишан. (Аларга) минем сүзем: шушы килеп җиткән ни бу кем Мөхәммәт углы Шәех Әхмәт, дәхи Шәех Әхмәтнең углы Әбдал, дәхи Сәет Әхмәт энесе Мөхәммәтнең углы Муса, Сәет углы Ягъкуп энесе Буланс, дәхи энесе Нурсәет. Шушы җиде кеше безгә килеп баш ордылар. Борынгы хан агаларыбыздан бирле тархан булып килгән кешеләр икән. Без дәхи мәрхәмәт кылып, бу сөйләнгән кешеләрне Тәңре Тәгалә ризасы вә Мөхәммәт пәйгамбәрнең шәфагәте өчен тархан кылдык. Моннан соң бу сөйләнгән кешеләргә юлларында, сәфәр чыкканда вә өйдә торган чакларында (кыскасы, һәрва-

кытта) аларның кешеләренә, җирләренә, йөк һәм хайваннарына һичкем вә һичбер яктан явызлык белән катышмасыннар, кагылмасыннар. Ясак, калан, салыг, мөсми (аларга) салмасыннар. Кулуш, колтка, баҗ һәм хәреҗ- хәраҗәт (алардан) алмасыннар. Мал вә мөлкәтләренә, бакча һәм җир-суларына кул озайтмасыннар. Өйләренә көчләп илче, кунак кундырмасыннар. Авыл салымы, җир түләме, морҗа салымы алмасыннар. Азык- төлек вә хайван азыгы сорамасыннар, һичбер яктан (аларга) кимчелек вә зарар тидермәсеннәр. Буш чакларында тыныч торып, кич-иртә, көндез һәм төндә безгә вә безнең нәселләребезгә дога вә алкыш кылсыннар, һичбер төрле көчләү, кысынкылык, зәхмәт вә борчу тидергән кешеләрнең үзләренә яхшы булмас дип, ал нишанлы ярлык бирелде. Тарих тугыз йөздә егерме тугыз да, мөбарәк сәфәр аеның унөченче көне иде.

Нишаны: Бисмиллаһы иррахмани иррахим. Ля илаһы илляլаһы Мөхәммәдур Рәсулулла. Әс-солтанлы әгъзам гыйззәуд дөнья вәддин әбулмәз һәр Сәхиб-Гәрәй баһадир хан. Хәлляделляһу мөлкәһу вә эиидә Солтанә тәһу.»

Җәяләр эчендәге сүзләр С.Вахиди тарафыннан, ярлыкның ертылган һәм таушалган урыннарында яки өстәмә аңлатмалар рәвешендә язылган. Башка тәрҗемәләрдә булган кебек үк, бу китерелгән текстта да ялгыш хәрефләр, дөрес үк укылып бетмәгән урыннар булуы мөмкин. Ләкин тарихчылар өчен бу артык зур әһәмияткә ия түгел, иң кыйммәтлесе — аның эчтәлеге. Югарыда С.Вахидинең «Исследование ярлыка Сахиб-Гирей хана» дигән мәкаләсе «Известия общества археологии, истории и этнографии» басмасында урнаштырылганы әйтелгән иде. Бу зур тикшерүдә ярлыкның эчтәлеге, язылу формасы, кемнәргә бирелүе, язу әсбаплары (карасы, кәгазе һ.б.), орфографиясе һәм каллиграфиясе, мөһере, сүзләре, теле һәм стиле анализлана һәм бик күп искәрмәләр бирелә.

Эчтәлегеннән күренгәнчә, Сәхибгәрәй хан бу ярлыкны һиҗри белән 929 ел мөбарәк сәфәр аеның унөченче көнендә Мөхәммәт исемле кешенең балаларына биргән. Миляди исәбе белән бу вакыт 1523 елның 2 гыйнваренә туры килә. Ярлык нинди иҗтимагый- сәяси хәлне ачыклый соң? Текста язылганча, Мөхәммәт тарханның балалары кулында малмөлкәт, җир-сулар һәм кешеләр калган Кешеләр дип феодаль заманда хуҗаның якын—яраннарын да, аңарга бәйле хезмәтче һәм иген игүчеләрне дә атаганнар. Кара кешеләр һәм аксөяк кешеләргә бүленеш яшәп килгән. Аксөякләрнең, бу урында Мөхәммәт һәм Шәех Әхмәтләрнең маллары, терлек-туарлары, җир-сулары һәм кешеләре булса, шуның

өстенә алар һәр төрле салым-налоглардан азат ителгәннәр. Байлыкларыннан, керемнәреннән бер нидә түләмәгәннәр. Ә бит бик күп кеше мондый тарханлык ярлыгы ала алмаган, ярлыкта күрсәтелгән барлык салымнарны да күтәрергә мәҗбүр ителгән. Әгәр шулай түгел икән, налоглардан азат итү турында ярлык биреп торуның кирәге дә булмас иде. Шуның белән бергә, документ бай феодал-тарханнарның мал-мөлкәтләрен дә, шәхси иминлекләрен дә саклый, һичкем аларга җәбер-золым кылырга тиеш түгел, җир- суларына кул сузмаска тиеш. Әгәр кем дә булса аларны кыерсытса, үзләренә яхшы булмас, диелә. Димәк, андый хәлләр очрап торган, кешеләр бай феодалларны кимсеткәннәр дә, үз хокук һәм ихтиаҗлары өчен даулашканнар да. Ә дәүләт үзенең документаль акты белән тархан-феодалларның мәнфагәтен яклап һәм саклап чыккан. Моннан нәтиҗә шул: Казан ханлыгы иҗтимагый - сәяси аспектта каршылыклы феодал дәүләт булган.

Ханны, дәүләтне гаскәри көчләр саклаган, ә эчке тормышта югары сыйныф вәкилләренең мал- мөлкәтен, хокукларын кемнәр саклаган? Ярлыкта төрле исемдәге хезмәткәрләр барлыгы әйтелгән. Алар барысы да дәүләт чиновниклары. С. Вахиди искәрмәләре буенча: әмир- бәк (урысча князь), хаким -өлкә судьясе, Сәед - өлкән рухани, казый - халык судьясе, мөхтәрәм хуҗалар - урындагы руханилар, вәкаләт ияләре һәм мәэмүрләр - полиция чиновниклары.

Урам башлыклары, бакчачы һәм көймәчеләр дә гади кешеләр түгел. Юкса, нигә гади бакча караучыга, көймә йөртүчегә салым—түшем салмаска? Нигә аларга беренче чиратта мөрәҗагәть ителә? Чөнки алар бакчачылык, суда йөзүче караб-көймәләр өчен җаваплы һәм тамга (таможня) бәясе җыючы чиновниклар. Ә токтаул һәм тамгачылар базарларда эш иткәннәр, берсе тамга салып салым алган, икенчесе тәртип саклаган, кирәк булса, кулга алган. Урам башы (постовой) урамнарда, мәйданнарда тәртипне күзәткән, кирәк булса, җәзага тарткан. Шулай итеп, алар дәүләтнең эчке тәртибен һәм җәмгыятнең тынычлыгын, гомуми мәнфагәтен сакларга тиеш булганнар.

Ярлык алган тарханнар нәселдән килгән бай мөлкәтле кешеләр булганнар. Сәхибгәрәй үзенең ярлыгында «борынгы хан агаларыбыздан калган тархан икәннәр» дип яза һәм аларның хокук һәм өстенлекләрен тагын бер кат раслый, тарханлыкларын дәвам иттерә. Димәк, бу нәселдән нәселгә күчүче хокук булган. Чыннан да, эре феодаллар үз гаиләләренең өстенлекләрен саклау өчен тырышканнар, шуңа хезмәт иткәннәр.

Сәет Вахиди ярлыкның байтак сүзләренә искәрмә-аңлатмалар бирә. Шулар арасыннан бер генә сүзгә «суюргал» терминына тукта-

лып китик. Чөнки тарихи әдәбиятта «суюргальная система» дигән төшенчә бар. Бу сүз әлеге ярлыкта һәм тагын бер язмада «суюргап» дип тә язылган. Вахиди В.В. Радлов фикеренә таянып, бу сүз «милость, милостивый подарок», ягъни шәфкать яки мәрхәмәтле бүләк дигәнне аңлата, «пожалование» бүләк итү, ди.

Ни өчен бүләк? Әлбәттә инде, нинди дә булса хезмәт өчен. Ләкин кызганыч, Ибраһим хан ярлыгы да, Сәхибгәрәй хан ярлыгы да тархан булган кешеләрнең, аларның ата- бабаларының да, ханга яки дәүләткә нинди зур хезмәт күрсәтүләрен әйтми. Шунлыктан, алар бүләкне хәрби хезмәт өчен генә алганнар дип әйтә алмыйбыз.

Йомгак ясап шуны әйтәсе килә: Сәхибгәрәй хан ярлыгы дәүләти акт буларак бүген дә актуаль, безнең Татарстан республикасы өчен хезмәт итә ала.

«Зафер наме-и вилайет-и Казан» Шәриф Хаҗитархани.

Шәриф Хаҗитарханинең Казан шагыйре икәнлеген һәм аның югарыда исеме аталган әсәрен Төркия солтаны Сөләйман Канунига (Законодатель) җибәргәне турында Төркиядәге татар галимнәре Зәки Вәлиди һәм Нигъмәт Курат әсәрләреннән укып белә идек.(16) Шагыйрнең исеме әдәбият хакында сөйләгәндә, язганда әйтелеп киленде, ләкин шигырьләре, аларның хәзерге телгә тәрҗемәләре бүген дә әле юк дисәм, шаять, ялгышмамдыр. Зәки Вәлиди аның әсәрен (ә анда байтак шигырьләр бар) үз телендә, ягъни XVI гасыр телендә бер нинди искәрмәләрсез һәм аңлатмаларсыз бастырган. Нигъмәт Курат шагыйрьне искә алып, аның Казаннан Истанбулга поэма җибәрүе турында һәм, әгәр дә ул урыс явы вакытында һәлак булмаган булса, үзен тагын да ишеттергән, язганнарын тагын да җибәргән булыр иде дип күрсәтте.

Төркия галиме Мелек Үзйетгин Шәриф Хаҗитарханинең әсәрен төрек теленә тәрҗемә итеп бастырган һәм төп нөсхәсенең фотокүчермәсен безгә, Казанга җибәргән. Фәрит Хәкимҗанов урысча тәрҗемә ясап, «Гасырлар авазы» журналының 1995 елгы 1 санында бастырды. Хәзерге татарчага тәрҗемә авторны кетә, бугай. Без әнә шул урысча басмадан файдаланып, әсәрнең эчтәлегенә караган кайбер фикерләребез белән уртаклашырга булдык.

Югарыда язылганча, әсәрнең исеме «Зафер наме-и вилайет- и Казан». Хәзерге татар теленә күчергәндә «Казан иле җиңүенең бәяны» дию яхшы булмасмы? Әлбәттә, төрлечә әйтергә мөмкин: Казан дәүләтенең җиңү кыйссасы», «Казан өлкәсенең җиңү хөтбәсе», «Ка-

зан ханлыгының җиңүенә мәдхия». «Зафер» дә безнең телдә Зөфәр дип әйтелә. Ләкин аңа исем бирү минем вәкаләтемә керми.

Әсәр Мәскәү патшасы Иван IV нең Казан шәһәренә һөҗүм итүе һәм ике арадагы сугышта Иван гаскәренең җиңелүе турындагы вакыйганы тасвирлый. Билгеле ки, бу сугыш 1550 елның 14-25 февралендә була. Урыс елъязмалары әлеге сугышның Иван өчен уңышсыз бетүен һава шартларының начар торуы белән аңлата. Янәсе, кинәт җылытып җибәргән, җепшек кар, яңгыр яуган. Ләкин вакыйгаларның үзәгендә кайнаган Шәриф бу турыда бер нәрсәдә әйтми. Андый хәл булса, мөгаен, ул аны язмый калмас иде.

Язучы башта Болгар иленең урынын билгели. Аннан соң Болгар иленең башкаласы Казанның бик матур һәм шифалы, ислам дөньясындагы бөек шәһәрләрнең берсе булуын, башка мөселман илләреннән еракта, шул ук вакытта денсезләр иле белән чиктәш торуын яза. Казан ханы «Әбел-Гази Сафа— Гәрәй Баһадир хан» ислам динен яклап, хак булмаган динне тотучыларга каршы сугышты дип, кереш сүз дә ясый. Бу урыннарны Коръәннән аятләр, бәетләр һәм шигъри юллар белән бизәкләп бара. Мәсәлән, Сафагәрәй хан турында «әгәр җәфалаучылардан үч алмасам, үзем җәфалаучыга әйләнермен, дип әйтә дә, үзенең сугышчан атын иярләп, биленә зиннәтле, дошманнарын кыра торган кылычын тагып, ислам дине өчен сугыш юлына басты», ди. Һәм шунда ук «Аллаһы Тәгалә үзенең ярдәмен кемгә теләсә, шуңа күрсәтә», «Аллаһы Тәгалә ярдәме белән зур булмаган гаскәриләр төркеме бик зур гаскәрләрне дә җиңделәр» дип, ханның рухлануын билгели. Ә динсезләр, кяферләр язмышның хәерсез вакыйгаларыннан канәгать булып, бу пычрак дөньяның әхваленә шатланды, дип яза автор. Мактанчылык белән борын чөеп, алтын тудырган җәмгыять башбаштагы алласыз Иван бик күп гаскәр җыйды, аларны мылтык һәм туплар белән коралландырып, бөек Казан шәһәренә килде һәм аны камап алды. Шунда бер газәл китерелә.

«Гаҗәп! Дөньяның иң күңелле урыны бу Казан,
Дөньяда юк мондый шәһәр, торак бирүче.
Дөньяда юк шундый чәчәк атучыдай Казан,
Казанда һәрвакыт аш-су табарлар,
Шундый ул галәм шәһәре Казан.
Хан бабайлардан безгә калган безнең дәүләт,
Бу урын - җирдә һәрвакыт хан шәһәре,
Хан утының урыны.
Җирен һәм өен сатып атасы салымын түләмәс,

Нигә соң монда бу явыз, ул Иван шәһәре түгел!
Шәрәфи, ташлама аны, әгәр ышансаң җиңүгә,
Әйтсәләр дә бу көннән «ул хуҗа шәһри Казанга».

Шагыйрь Шәриф Хаҗитархани ничек язган? Аны әдәбиятчы галимнәр тикшереп, хәзерге телебезгә күчереп төгәл мәгънәсен бирерләр әле дип ышанабыз. Мин исә бередә, әйткәнемчә, Ф. Хакимҗановның урысча тәрҗемәсеннән генә файдаланам.

Алга китеп, автор Казанны яклап сугышучы баһадирлар турында сөйли. Алар арасында моңа кадәр безгә билгеле булмаганнары да бар. Әйтик, ул болай яза. Крепостьның бер капкасын, егетләрне бергә туплап, бу дәүләтнең терәге булган Булат бәкнең углы Мамай бәк Нургали морза белән (аларның даны артсын) сакладылар һәм батырларны да җиңделәр. Хан капкасын сугышчан батырлык остасы, гайрәтле дәһшәт иясе Козыҗак углан саклады. Аллаһы аның батырлыгын арттырсын. Башка капкаларда каһарманнар җитәкчесе Искәндәр батырчылыгы белән Ак Мөхәммәт углан сугышты. Аллаһы аның гомерен озайтсын. Тагын да башка капкаларда Котби әл Актаба оныгы Сәет Ата, мәрхум Сәетнең углы Кол Мөхәммәт Сәет шәкертләрне, руханиларны һәм суфиларны җыеп, сугышка әзер торды. Барбулсын аталык шәһәрнең башка капкаларында сугышты. Шәһәр бәге, Болгар вилаятенең идарәчесе, хан казнасының башлыгы, әмирләр нәселеннән булган Бәйбарс бәк арка күрсәтмичә, арсландай көч белән дошманнарга каршы торды. Кайсыбер билгеле баһадир сугышчылар Нарики бәк, Ай Килде бәк һәм Ак Матай бәк, хаҗилар җәмгыяте (ходай аларга ярдәм бирсен),кайда дошман һөҗүм итә, шул җиргә җитешеп, каһарманнарча сугыштылар. Шуннан соң бер мәснәви тәкъдим итела:

Гаскәри төркемнәр таулар кеби төзелгән,
Диңгез дулкыннарыдай.
Аягы - башы көпедә Рөстәм сөңге белән,
Аяктан башка кадәр тимер эчендә,
Һәръяктан арыслан сугышчылар,
Үзләренең җәя - уклары белән.

Автор урысларның шәһәргә туплардан атуларын да тасвирлый. Аларның 11 утлы пушкалары, 4-5 һава туплары бар иде, беренчеләренең ядрәләре һәртөрле нәрсәләр белән тулган, ак нефть, җиз, күкерт, 4-5 кургаш ядрәләре (моңа Аристотель үзе гаҗәпсенер иде), һәм икенчеләре зур таш ядрәләре ыргыттылар, ди. Бу соңгыларының ката-

пультталар булуы мөмкин. Урыс елъязмаларында мондый корал (һава туплары) турында мәгълумат очрамый.

Кыскасы, дип яза автор, ике гаскәр тимергә чумып, бертигез торып, бер- берсе белән 16 көн буе сугыштылар, һәм түбәндәге мисрагны китерә:

Бу шундый сугыш булды ки —әйтерсең мәшхәр,
Җир кылыч тавышлары белән тулды,
Казан шәһәрендә кан елга булып акты.

Ахыр чиктә мөселманнар Аллаһы ярдәме белән җиңделәр, кяферләр үтерелделәр, таратылдылар һәм чигенеп качарга мәҗбур ителде. «Бу вакыйга 957 елның мөхәррәм аенда булды. Бу кыйммәтле язманың авторы һәм кәгазь битләрен пычратучы, колларның иң ярлысы Шәриф Хаҗи Тархани». Бу җөмлә авторның язмадагы соңгы сүзләре.

Китерелгән текстан күренгәнчә, Иван IV һава шартлары уңайсыз булуы аркасында түгел, ә Казан гаскәренең каһарманнарча сугышуы нәтиҗәсендә җиңелеп чигенгән һәм кайтып киткән икән.

Гомумән алганда, бу әсәр тарихи чыганак итеп файдаланырга бик лаек. Безнең фаҗигале хәлләрне үз күзе белән күргән кешегә ышанмаска хакыбыз юк. Әлбәттә, биредә үз иленңне күтәрү, аны яклап язу тенденциясе бардыр, чөнки үз ватанын кем генә яратмаган да кем генә хәзер яратмый.

Әсәрдә тагын бер нәрсә бик ачык күренә: автор зур эрудиция, көчле интеллект иясе булган. Ул Аристотельны да, Александр Македонскийны да, бик күп китапларның эчтәлекләрен дә яхшы белгән. Коръәнне инде әйтеп торасы да юк, ул аның сүрәләрен һәм аятләрен яхшы аңлап, әсәрендә тиешле урынын табып, киң кулланган. Шагыйрь буларак, шулай ук шигъри әмәлләрдән оста файдаланган. Язмада кыйтга, бәет, газәл, мәснәви жанрлары, мәкальләр кулланылган, алардан 22 өзек китерелгән.

Әсәрнең әһәмияте бик зур. Авторның «Казан Болгар вилаятенең башкаласы» дип санавы үзе генә дә ни тора! Аны әле тарихчылар, әдәбият һәм тел галимнәре, әлбәттә, башкалар да өйрәнер дигән өметтә калабыз.

Җир мөнәсәбәтләренә караган татарча язмалар.

Казан ханлыгы чорында күп төрле язмалар гамәлдә йөргән, ләкин безгә бик азлары гына килеп җиткән дип әйткән идек. Мәсәлән, җир мәсьәләренә кагылышлы килешүләр, гаризалар язылган. Аларның да

урысча тәрҗемәләре генә сакланып калган. Без үз вакытында татарчадан урысчага тәрҗемә ителгән документларның кайберләрен яңадан татарчага күчереп монда урнаштырырга булдык. Әлбәттә, XVIII гасырда татар язуларын урысчага күчерүчеләр дә, шулай ук без дә оригинальдән бераз читләшәбез, ялгышлар җибәрәбездер. Мәсәлән, исем- фамилияләр, авыл яки кыр, елга исемнәрен бирүдә шулай булуы мөмкин. Урысча тәрҗемәләр татарчаны бигрәк тә нык бозалар. Шуның өчен (укучыдан гафу үтенәбез) безнең төп максат тел мәсьәләләре түгел, ә тарихи проблемаларны хәл итәргә тырышу.

Түбәндә сүз алып барылачак урысча текстларны иң беренче булып Н.Н.Ардашев үзенең «Татарские земляные письма XV в. и спорное дело XVIII в. о ясашных землях» дигән мәкаләсендә китергән. Ул исә «Записки Московского археологического института» китабында басылып чыккан. (17) Икенче мәртәбә аларны В.Д. Димитриев «Документы по истории народов Среднего Поволжья XVI- начала XVII веков» дигән (18) һәм өстәмә итеп үзе тапкан яңа документны «Земельный документ времен Казанского хана Сафа- Гирея» дигән мәкаләсендә (19) бастырып чыгарды.

Хәзер урысча текстларның татар теленә тәрҗемәләрен берәмберәм карап чыгабыз, аннары аларга бирелгән искәрмәләр белән танышырбыз.

Ходай- Бирденең «умарталык» биләмәләрен Кошма Сәбигә сату язуы. 1538- 1539 еллар.

«Бу җир язуы 945 елда язылды. Мин, Ходай-Бирде, фәкыйрьлегем аркасында тамгалы ике җиремне Кошма Сәбигә саттым. Шул тамга җирләрем өчен алты батман бал һәм илле тиен акча алдым. Ә тамгаларым шундыйлар.... Тагын әле тамгалы биш җиремне саттым.... Алар өчен унике батман бал алдым. Ул җирләрнең межалары Кунар елгасының Зур Кингар елгасына кушылган урынында. Кингар елгасының ике ягыннан да урманга йөриләр. Кошма Сәбигә мин барысы җиде тамга саттым һәм киләчәктә бу җиргә беркем дә дәгъва кылмасын өчен, бу язуны бирдем.

Ә таныклык бирүчеләр Тойҗа Акмашәех һәм Үтәш, аларга шуның өчен Тойҗәгә бер сусар, Акмашәехкә бер төлке, Үтәшкә бер сусар бирдем. Язды Хуригәрәй.»

«Умарталык» биләмәсе- урман эчендәге агачлык һәм куаклыкларда кыргый бал кортларының оялары тупланган урын. Агач каүсәләрендә урнашкан умарталарның балын кешеләр күпләп җыеп ала торган бул-

ганнар. Бу җирләр ясаклы җирләр рәтенә кермичә, кешеләрнең нәселдән нәселгә кала торган үз җирләре дип саналган (урысчада вотчина) Шул ук җир мәйданында сөрү җирләре дә, печән чабу урыннары да булган. Кай вакыт алар бик зур җирне, хәтта меңгә якын гектарны биләп торганнар. Мондый урманлы җир мәйданын урыслар «бортные ухожаи» дип атаганнар («борть» сүзеннән). Бу биләмә җирне, ясак җирләреннән аермалы буларак, сатарга, бүләк итәргә, мирас итеп калдырырга яраган. Ә ясак җирләрен авыл җәмгыяте ризалыгыннан башка алай эшләргә мөмкин булмаган.

Һиҗри календаре белән 945 ел хәзер без куллана торган Григориан календаренең 1538-1539 елларына туры килә. Бу документларның урысча тәрҗемәләрен беренче мәртәбә бастырып чыгаручы урыс архивисты Н.Н.Ардашев борынгы «дөнья яратылудан» башлана торган календарь нигезендә уйлап 945 алдына 6 санын (6945) куя һәм аннан 5508 не («дөнья яратылудан» башланган календарь белән Григориан календаре арасындагы аерма санын) алып ташлап, 1437 не чыгара. Аңа урысларның зур тарихчылары М.Н.Тихомиров, И.Д.Кузнецов һәм башка кайберәүләр иярде. Бу хәл аларның татарлар Казан ханлыгы чорында һиҗри календаре буенча яшәүләрен белмәүләреннән, яки белеп тә аңа игътибар итмичә урыслаштыру тойгысыннан киләме, әйтүе кыен. Чөнки язмада дөрес бирелгән һиҗри 945 ел безнең хәзерге календарьнең нәкъ менә 1538- 1539 елларына тәңгәл.

Һәрбер кешенең үз тамгасы булган кебек, җирләренең дә тамгасы булган. Тамга дип җирнең бер мәйданын, зурлыгын да пай рәвешендә санаганнар. Урысчада ул «знамя» дип йөртелгән. Пай өлеше яки тамганың мәйданы төрле җирдә төрлечә булган. Шуның өчен аларның зурлыгын хәзерге берәмлекләр белән исәпләү бик кыен. Тамгаларның рәвеше язмаларда күрсәтелгән, без ул урыннарда нокталар куеп уздык.

Батман дигән үлчәү берәмлеге урынына карап та, аерым әйберләр өчен дә төрлечә йөргән. Бу язмада телгә алынган Казан батманы бал өчен пот ярым (24 кг) исәпләнгән. Язудан күренгәнчә, сатучы җире өчен 27 пот (18 батманны 24 кг. га тапкырла), ягъни 432 кг= 4 ц. 32 кг бал алган (1 пот 16 кг исәбеннән.) Мондый хәл бер яктан, балның бик күп җыелганын күрсәтсә, икенче яктан, җир сатучының сәүдә эшенә бирелеп киткәнен дәраслый булса кирәк. Шул кадәр балны сатучы гаиләсе белән дә ашап бетерә алмагандыр. Салым түләргә дә алай күп китмәгән. Димәк, бердән бер юл сәүдә кала.

«Межа» сүзе татар аңлатмалы сүзлегендә «ызан» дип аңлатылган. Икеседә кулланышта булганлыктан, без аның документ телендәге-

сен калдырдык.

Таныклар дип таныклык (Свидетельство) бирүчеләрне атаганнар. Таныклык бирүчеләр, язмадан күренгәнчә, байтак табыш алганнар. Һәрхәлдә хәзерге нотариаль контора кешеләреннән калышмаганнар ахры. Алар алган «сусар, төлке, тиеннәр» җанварларның үзләрен түгел, ә аларның тиреләрен яки эшкәртелгән мехларын белдергән.

Тобулай Тобалан углы, аның абзыйлары Свергузя
һәм Тартайның килешү язуы. XVI гасырның 30-40 еллары.

«Сәнәи 6966. Бу шартнамә Мөхәммәт Әмин углы Сафа-Гәрәй хан заманында мөселман әһеле тарафыннан татарча язылды Тобалан углы Тобулай һәм аның абзыйлары Свергузя һәм Тартай— өч туган агаэнеләр— үзебезнең иманыбыз буенча түбәндәге үзара килешүне төзедек: безгә һәм безнең балаларыбызга, туганнарыбыз һәм кардәшләребезгә бер нинди каршылыксыз, бер- беребезгә зыян китермичә, бергәләп ясак түләргә. Бу шартнамәне Тобалан углы Тобулай һәм аның абзалары Свергузя һәм Тартай үз кулларында тотарга (тиеш). Без үзебезнең дүрт тамгадан торган сөрү һәм печән басулары турында шулай дип әйттек.

Ә ул биләмәнең мәйданы болай: Шелюпшер елгасының ике ягы буйлап печән чабу һәм сөрү җире. Зур Була елгасы җиренә, аннан бер якта балык тоту елгасы буйлап Кара күлгә һәм Дала коры елгасына кадәр. Аннан соң умарталы агачка агучы чишмәдән башлап Кара күлгә— алар бер урынга агалар— Һәм Тонсюр елгасының ике ягы белән кара куаклык һәм урманга кадәр. Тагын Ипиле чокыр куаклыгындагы күлгә кадәр, анда чик (багана -?) Аннан Бура елгасы чиге. ә Бура елгасы Зур Безднәгә коя, аның ике ягы буйлап чик. Абичи Безднәдә чик, тагын Нурдештә ике яктан иске торакта чик һәм Кече аланга барып Пәле чокырында чик. Ике яклап, башыннан ахырына кадәр алып Безднә тамагына, Ташлы кичүгә кадәр сул яктан чик. Балык тоту урыннарын кертеп тагын Ак Безднә башында ике яклап чик вә тагын ике яклап Кече Кирләдәге чик, тегермәне белән Зур Кирлә чокыры башыннан алып ахырын да кертеп печән чабу һәм сөрү җире. Әбамзе елгасының ике ягы, тегермәннән алып Кучак кырына кадәр печән чабу һәм сөрү җире. Тутарлы аланына кадәр, Түкә елгасының ике ягыннан да килеп, Түкә елгасына кушылучы Вәттак коры елгасында чик. Тагын Зур Кишнәр, Урта Кишнәр, Кече Кишнәрдә чик. Харошеин урманы янында чик. Карли башында чик, Карабай башында ике яклап чик. Аборши башыннан Өрәнге аланы-

на вә карурман Кошкудыда чик, аннан егылган имәнгә кадәр. Алан уртасында кызыл балчык алалар, анда күл бар, аның каены янында чик. Ул каеннан якын аланда куаклык, анда тагын сәнәккә охшаган каен, аннан Имә авылына. Ул авылда келәт, нараты янында чик. Зур Була елгасында чик. Аның бер ягында басу кыры вә печән җире, балыклы су. Урманында һәртөрле җәнлек һәм эшкәртелгән агачлары белән умарталар вә аю, бүре, куян, төлке, кондыз, сусар, капкын һәм кош ятьмәләре, тукмаклар бар.

Тобалан углы Тобулай вә аның абзалары Свергузя һәм тагын да Тартай ул җир өчен ясак түләүләр буенча бернинди бәхәс кыйлмаска, туган кардәшләребезгә беркемгә дә сөрү җирләребезгә, печән чабу һәм башка урыннарга кермәскә, әгәр кем дә булса ризалашмыйча дәгъва кыйлса, аларны тыңламаска.

Таных булдылар:
Шәһит мафа Агиш углы Якбилдар -таныклык өчен ун алтын акча алды.
Шегилфа морза Бәхтияр углы Аргиер таныклыкка калфак алды.
Тагын Тәгать мафа Ясиләк углы Агиш танык булды, төлке бүрек алды.
Шегәт мафа Сәфәр углы Ләеп төлке алды.
Әдегән углы Адыш Хотил язды һәм эше өчен Тобулай аңа ун алтын бирде.
Мин, Акбатыр, танык булдым һәм үземнең тамгамны салдым.
Акия танык булдым, үз тамгамны салдым.
Мин, Акиш, танык булдым һәм тамгам салдым.
Мин, Свергузя, үз балаларыма яздым һәм бүлеп бирдем.
Мин, Тартай, балаларга яздым һәм бүлдем, һәм бирдем.»

Бу бераз буталчык һәм аңлашылып бетми торган язма татарчадан урысчага тәрҗемә ителгән рәвештә 1802 елда Сембер Губерниясе межалау конторасына бирелә. Чөнки документта күрсәтелгән җирләр турында каршылыклы фикерләр һәм бәхәс туган була. Аның төп нөсхәсе югалган дип исәпләнә, кем тәрҗемә иткәне дә билгеле түгел. Ләкин аның татарча тексты булганы да, тәрҗемә ителгәне дә шик тудырмый. Ул турыда башка архив материаллары да дәлилле итеп сөйли. В.Д.Димитриев мисаллар китерә: 1704-1705 елларда ук Тойбула, Свергузя Тобулаевларның оныклары татарча язылган документ нигезендә шул җирләрнең хуҗалары икәнлекләрен исбатлыйлар, анда күрсәтелгән чикләрдә чик баганалары һәм чокырлар казып куелганын раслыйлар һәм «татарча җир язуындагыча» эшләнгәнлеге турында әйтәләр, ди.

Язмадагы 6966 ел ялгыш булырга тиеш. Бу безнеңчә 1457-1458 елларга туры килә. Ә шунда ук Сафагәрәй заманында язылды дип куелган. Тәрҗемәче яки күчереп язучылар, гадәттәгечә диярлек, сүзләрне генә түгел, елларны да урыслаштырырга тырышып бутап бетерәләр. Һиҗри буенча бу сан, бәлки, 956 булгандыр. Ә ул - Сафагәрәй ханның үлгән елына, 1549 га туры килә. Язманың вакыты Сафагәрәй заманы булгач (ә ул Казанда 1524-1531, 1535 -1546 һәм 1546-1549 елларда хан булып тора), документның датасын XVI гасырның 30-40 дип куярга хакыбыз бар.

Язучы яки тәрҗемәче Сафагәрәйне Мөхәммәт-Әмин (Махабмет-Имин) углы дип тә ялгыш яза. Тарих фәне исбатлаганча Сафагәрәй Кырымның атаклы ханы Миңле- Гәрәй улы Фатыйхгәрәйнең улы була. Миңле-Гәрәйнең Мөхәммәтгәрәй, Мәхмутгәрәй, Сәгадәтгәрәй, Фатыйхгәрәй исемле уллары туа. Мөхәммәтгәрәй углы Сәхибгәрәй 1521-1524 елларда Казан ханы булып тора. 1524 елда Төркиягә китә һәм үзенең урынына Казан ханы итеп туганнан туган энесен калдыра.

Язманың төп мәгънәсе нәрсәдә соң? Ул шундый зур җир мәйданы өчен ясакны «үзара каршылыксыз һәм бер - берсенә зыян китермичә» бергәләп түләү турындагы документ булып тоела. Ләкин икенче төрле фикерләр дә туа. Бу туганнан туган өч кеше арасында берсе — Тобулай башлап йөрүче, хәлиткеч кеше кебек күренә: язмада ул туганнары арасында беренче урынга куелган, килешүне язучыга акчаны ул бирә, язма ахырында туганнары Свергузя һәм Тартай кулларын куя,ә Тобулай куймый. Тегеләре балаларына нәрсәдер (билгесез) бүлеп, язып бирәләр, ә Тобулай бер нидә бүлеп язып бирми. Свергузяның үз балалары булган, ә Тартайның үз балалары булмаган кебек, ул балаларга гына, ди.

Шундыйрак томанлы мәсьәлә— биләмәнең мәйданы. Аның хәзерге Татарстан республикасы Буа районындагы җирләр икәнлеге аңлашыла. Ләкин мәйданның бик күп чикләр белән чикләнгән булуы ачык күренеш тудырмый. Шул ук вакытта үз заманы өчен бу язма җайлы гына аңлашылгандыр. Чикләрнең баганалар, чокырлар белән билгеләнүе дә булган, аларда хуҗаларның тамгалары да ясалгандыр. Бу турыда башка чыганакларда мәгълуматлар бар.

Документ күрсәткәнчә, авыл кешеләре җир сөреп иген иккәннәр, кышка күп кенә печән хәзерли торган булганнар. Бу хәл печәнлек җирләрен һәрвакыт истә тотуда, хәтта кайвакыт сөрү җиреннән алда язуда да күренә. Урманнарның бик бай булуы да язмада ачык чагылган.

Язмада «эшкәртелгән агачлар» дигән сүзләр бар. Кешеләр кыргый

бал кортлары оялаган төмсә, корыган —корып бетмәгән агачлардагы куышларны киңәйтеп зурайтканнар, кортлар өчен иркенлек ясаганнар, җитәрлек итеп тишек калдырганнар, зурайган тишекне такта белән томалап калдырганнар. Болай иткәч, үзләренә бал алуы да җиңеләйгән. Әнә шундый агачларны «эшкәртелгән» дип атаганнар (урыслар - «дельное дерево» дигәннәр). Урманнарда төрле җәнлек, кош-кортлар хакимлек иткән. Документ аю, бүреләрдән башлап сусар, бурсык, тиеннәргә кадәр саный һәм ау коралларын - җәнлек, кош-кортларны тоту өчен куела торган ятьмәләрне һәм агачларга асылып куелган тукмакларның барлыгын әйтә. Бу тукмаклар белән агачларга шак-шок бәреп төшереп, алардагы алма, чия һәм чикләвекләр җыйганнар, ә кайвакыт ерткыч хайваннарны куркытканнардыр. Хуҗалыкта балык тоту да зур әһәмиәткә ия булган. Шунлыктан балык тоту урыннары да язма авторларының игътибарыннан читтә калмаган.

Инде таныклык бирүчеләр хакында. Алар арасында дәрәҗәле кешеләр күренә: бер морза, өч мафа. Соңгы сүз «мафа» - Әхмәт ага Булатовның Л.З.Будагов сүзлеге буенча аңлатуында дәрәҗә атамасы, салым һәм йөкләмәләрдән азат ителгән кеше. Фарсы теленнән безнең якларга сәүдәгәрләр аркылы кергән булырга тиеш. Гомумән алганда, тарханлыкны аңлата торган сүз.

Таныкларга түләү турында язганда «алтын» дигән сүз очрый. Ул—акча берәмлеге. XVI гасырда бер алтын өч тиенгә тигез булган. Димәк, ун алтын утыз тиенне аңлаткан. Таныклар арасында бер нәрсә дә алмаганнары да бар.

Документның тарихи әһәмияте ифрат зур. Ул Казан ханлыгы чорында кешеләрнең хуҗалык итү күренешен тасвирлый. Иҗтимагый-икътисади хәлләрне дә күзалларга ярдәм итә.

Янчура Хуҗалин, Байтимер Москеев һәм Исай Аднининнарның Яков Сутчин, Кадык Бәдаев һәм Сургач Зеняковларга каршы куелган гаризалары

«Мөхәммәт хан-патша заманында ата-бабаларыбыз нәсел буенча варисларга кала торган җир биләмәсен сатып алганнар һәм умарталы агачка үзләренең тамгаларын салганнар. Ата-бабаларыбыз безнең ул җирне кемнән һәм ничек сатып алганнар, без һәм аксакал картлар да белмибез. Шул вакыттан бирле хәзергә кадәр ул җирне һәм печәнлекләрне патшаның ата-бабаларыбызга бирүе буенча бернинди каршылыксыз, беркемнең дә дәгъва кылуын белмәенчә без биләдек. Ә хәзер иске хуҗаларына, ягъни Янчура Хуҗалинга, Байтимер Мос-

кевкә, Исай Аднинга бирдек. Алар ул җиргә һәм печәнлекләргә хуҗа булсыннар дип һәм безгә, балаларыбызга, туган-тумача кардәшләребезгә ул җирне иске хуҗаларыннан сорамасыннар, бәхәс кузгатмасыннар дип.

Язды Чуракай»

Бу язманың кайчан язылуы әйтелмәгән. Ләкин «Мөхәммәт хан заманында ата-бабаларыбыз» дигәннән XVI гасырның урталары дип уйларга нигез бар. Мөхәммәт Әмин Казанда хан булып 1478-1518 елларда тора. Аны аксакал картлар да хәтерләмәгәч, аңардан соң байтак вакыт үткән булырга тиеш. Бәлки бу язуны Казан урыслар тарафыннан яулап алынгач язганнардыр. Татарча язулар Казан дәүләте беткәч тә дәвам иткәнлеге турында башка күп мисаллар бар.

Шунысы кызык, бу документ бернинди дәүләти оешмаларга бирелмәгән, ә бары тик иске хуҗаларның үз кулларында гына калган, ягъни хуҗаларның үз хокукларын раслаучы язма булган. Бәлки соңрак Казан губерниясе Зөя өязе воеводасына бирелгәндер. Чөнки тәрҗемәнең тасвирында документның тәрҗемәсен шул өяз кешесе, Икенче Чирмешән авылы татары Роман (бәлки Рамазан булгандыр) Уразлин эшләгән икәнлеге әйтелгән.

Чураш Утяковның сөрү басуы һәм печәнлекләре белән «умарталык» биләмәсен Янчура Хуҗалиевкә, Аитовка һәм Яланали Чуреевка сату язмасы. 1562-1563 еллар.

«970 ел иде. Чураш Утяков әтиемнән калган Юргаш исемендәге җирем бар иде. Шуңа кушып тамгалы дүрт җиремне мин, Чураш, Янчура Хуҗалиевкә саттым. Аңардан мин бозавы белән бер сыер алдым. Межә Кама (Кашмаш) елгасының ике ягы буйлап, көньякта елганың башында бер якта Булакали елгачыгы, икенче якта Куганар елгачыгы. Ә дүрт межә эченә төрле җирләр керә: эшкәртелгән һәм эшкәртелмәгән бал агачлары, баллы, балсыз исән һәм егылган төрле агачлар, сөрү җирләре, һәм печәнлек урыннары, болыннары һәм балык тотарлык күлләр, төрле җәнлекләр урыннарын мин аңа хуҗа булырга бирдем. Шул турыда бу язуны биреп, мин, Чураш Утяков, балаларым, абыем, энем, туганнарым һәм башка кешеләр бу җирне Янчура Хуҗалиевтән сорап дәгъва кыйлмасыннар дидем. Әгәр кем дә булса дәгъва кузгатса, казыйлар (судьяләр) кабул итмәсеннәр һәм тыңламасыннар.

Таныклар булып торучыларга — Чурашка сусар, Аккүз Шургачевка шулай ук сусар, Кулай Табузиевкә бер калфак, Юсейгә ярты батман бал һәм сарык бирдем.

Язманы Мәмкәч Балтачев язды, аңа ундүрт тиен акча.

Һәм тагын мин, Чураш Утяков, тамгалы ике җиремне Чюреев балалары Янтай һәм Яланалиләргә саттым һәм шул тамгалар өчен егерме тиен акча алдым, ә тамгалар мондый...»

Бу документ шулай ук «умарталык» биләмәсе (бортный ухожай) турында. Алдарак ул турыда сүз булды. Язу вакыты һиҗри белән 970 ел диелгән. Безнең календарь буенча ул 1562-1563 елларга туры килә. Татарча мондый язулар соңрак гасырларда да дәвам иткән.

Беренче, өченче һәм дүртенче язмаларны 1727 елда Казан губерниясе Зөя өязе (Свияжский уезд) Икенче Чиремшән авылы татары Роман Уразлин татарча төп нөсхәдән урысчага тәрҗемә иткән. Бу турыда тәржемәләрнең тасвирламасында әйтелгән.

Югарыда карап үтелгән чыганаклар— дәүләти актлардан хан ярлыклары, шәхси юлламалар һәм җир биләмәләре турындагы документлар— безнең тарихи белемнәребезне арттыруга ярдәм итәләр. Алар аерым тарихи вакыйгаларны ачыклыйлар, халыкның иҗтимагый һәм икътисади тормыш халәтенең ничек булганлыгын күрсәтәләр.

### *Искәрмәләр*


1. РГАДА. Ф. 1173, оп. 1, д. 196, л.1.
2. Госманов М., Мөхәммәдъяров Ш., Степанов Р. Яңа ярлык // Казан утлары.- 1965- № 8.
3. Булатов Ә. Ибраһим хан ярлыгын укуга карата // Казан утлары.- 1966.- № 8.
4. Госманов М. Тагын Ибраһим хан ярлыгы турында// Казан утлары.- 1967.- № 6.
5. Усманов М. Татарские исторические источники.- Казань, 1972.
6. Старотатарская деловая письменность XVIII в.// Сост. Ф.С. Фасеев.- Казань, 1982.
7. Источники по истории Татарстана // Сост. С.Х.Алишев.- Казань, 1993.
8. Усманов М.А. Жалованные акты джучиева улуса XIV -XVI вв.- Казань, 1979.
9. Атласи Һ. Казан ханлыгы.— Казан, 1914.
10. Вахидов С. Ярлык Сахиб-Гирей хана // Известия общества археологии, истории и этнографии.- Т.XXXIII, вып. 1.
11. Вахидов С. Ярлык Сахиб- Гирей хана // Вестник научного обшества татароведения.- 1925.- № 1-2.
12. Баттал А. Казан йортында булынмыш тарихи бер документ. Сәхиб

—Гәрәй хан ярлыгы. //Turkiyat Mecmuasi, II.
13. Борыңгы татар әдәбияты.— Казан, 1963.
14. Мухамедъяров Ш. Ф. Тарханный ярлык Казанского хана Сахиб-Гирея. 1523 // Новое о прошлом нашей страны..- М.,1967.
15. Вахиди С. Сәхиб—Гәрәй хан ярлыгы // Безнең юл.- 1925 -№ 3.
16. Z.Y.Togan. Kazan xanliginda Islam Turk kulturu // Islam Turkleri Enstitusu dergisi- 1965 - C. II. S. 3-4, 194-195 ; Akdes Nimet Kurat. Rus Hakimieeti altinda Idil- Ural Ulkesi - Ankara Universitasi basimevi. 1968.
17. Ардашев Н.Н. Татарские земляные письма XV в. и спорные дела XVШ в. о ясашных землях // Записки Московского археологического института.- М. 1908, T.IV, вып. 1.
18. Димитриев В.Д. Документы по истории народов Среднего Поволжья XV- начала XVII веков // Ученые записки НИИ при Совете министров Чувашской АССР.- 1963.- вып. XXII.
19. Димитриев В.Д. Земельный документ времен хана Сафа-Гирея. Исторический сборник. // Ученые записки НИИ при Совете министров Чувашской АССР.- 1966, вып. XXXI.

## 2. Эпиграфик чыганаклар

### *Кабер ташы язмалары*

Татар халкының бик мөһим байлыгы бар. Ул да булса, кабер ташларындагы язулар— эпиграфик истәлекләр. Татар халкының байлыгы дип мин шуның өчен әйтәм, чөнки алар күрше славян- урыс, фин-угор халыкларында булмаган һәм юк. Чуашлар аларга бөтенләй битараф карый. Башкортларда да алар булмаган. Алтын Урда кабиләләре каберләр өстенә таш куеп, аңа язу язып калдырмаганнар. Мондый таш һәйкәлләрнең эшләнеш формалары, язмалары буенча бары тик болгар-татарларда гына булуын раслап, Идел буеның атаклы археологы А.П.Смирнов болай дип язды: «Кабер өсте язулары Алтын Урданың барлык өлкәләреннән бары тик Булгар җирендә генә таралган». (Смирнов А.П. Волжские булгары.- М., 1951 - С.55) Бу эпитафияләрнең нәкъ менә болгарларда таралуын тикшерүче галимнәр ислам дине, мәдәнияте һәм мәгарифе үтеп керүе белән аңлаталар. Чыннан да язулар гарәп хоруфатында булгач, гарәпләрдәге таш кую гадәте, аңа язу үрнәкләре, әлбәттә, әнә шул мәдәният йогынтысы булырга тиеш. Тирә- күрше халыклардан аермалы буларак, болгарлар ислам динен IX-X гасырларда ук кабул итәләр. Шунлыктан аларның кабер өстенә язулы таш куюлары аларга гына хас булып китүе бер дә гаҗәп түгел. Идел Булгарстаны җирендә беренче табылган яки укылган таш 1173 елда куелган булган. Ләкин ул сакланмаган. Аның текстын бер мулла укып күчергән һәм Н.П. Рычковка тапшырган. Н. П. Рычков үзе болай дип язган: «Биләр шәһәрчегендә иске ташлар күп, алар гарәпчә- татарча язылганнар һәм җирдә аунап яталар... Хәзерге Биләр кешеләре тарафыннан җимереләләр... Мин ул таштагы исемнәрне күчереп алдым... Ул җирләрне изге санап, ерак җирләрдән Мөхәммәт әһалисе, башкортлар да килеп гыйбадәт кылалар», ди. (Рычков Н.П. Журнал или дневные записки путешествия капитана Рычкова по разным провинциям Российского государства. 1769- 1770 гг.- СПб., 1770.-С. 21)

Шәһре Болгарның һәм Болгар йортының эпиграфикасы яхшы ук өйрәнелгән, күп кенә галимнәр бу турыда үз фикерләре белән уртаклаштылар. Без аны өйрәнү тарихына (историографиясенә) тукталып тормадык, чөнки темабыз Казан ханлыгы чоры чыганаклары. Ләкин бөтенләй үк кагылмыйча да булмас. Беренчедән, читләтеп үтәргә ярамый торган нәрсә - аны өйрәнүнең башланган вакыты. Бу эш 1722 елда

Петр 1 күрсәтмәсе (указы) нигезендә башлана. Петр шәһре Болгарда шул елны була һәм андагы тарихи истәлекләрне- кабер ташларын күргәч, аларны язып алырга һәм тәрҗемә кылырга боера. Аларның өчесен әрмәнчәдән урысчага Иван Васильев дигән әрмән тәрҗемә итә, ә татарчаларын кырык җиде таш язуын ахун Кадыйр- Мөхәммәт Сөнчәләев һәм Казан бистәсе тәрҗемәчесе Йосыф Ижбулатов шул боерык нигезендә күчереп ала һәм тәрҗемә итеп губернаторга тапшыра.

Икенчедән, Болгар- Казан кабер ташларын өйрәнү тарихын Һарун Вәли улы Йосыпов бик җентекләп тикшереп язып калдырды. Аның «Введение в булгаро-татарскую эпиграфику» (М.-Л.,1960) дигән китабында бу мәсьәлә яхшы яктыртылган. Анда аңа кадәр шул тарихны язучылар да күрсәтелгән. Ләкин алар барысыда урыс телендә язылган. Ф.С. Хәкимҗановның Һарун Вәлиевичны тел ягыннан тулыландырып язылган һәм соңрак чыккан «Язык эпитафий волжских булгар» (М.,1978) китабы да урыс телендә. Үзебезнең ана телебездә дә булсын әле дигән фикердән чыгып, без бу язмабызны укучыларыбызга татарча тәкъдим итәбез. Татарча язылганлыктан, биредә без таянып язган Һарун Вәлиевичтән күчерүләр дә булыр.

Һ.В. Йосыповның төп максаты Казан ханлыгы истәлекләренең Болгар дәүләте ядкәрләре дәвамы булуын исбат итү иде. Һәм ул бу бурычны бик яхшы үтәп чыкты, чөнки ул ядкәрләрнең тикшерү нәтиҗәләрендә тәнгәл килүе ап—ачык иде. Моңа өстәп тагын бер принципиаль мәсьәләнең чишелүен дә әйтергә кирәк. Галим XIV йөздә Болгар дәүләтенең феодаль таркаулык кичерүен, төрле әмирлекләргә бүленүен таныды һәм аны эпиграфик материал җирлегендә раслады.

Билгеле булганча, XIV гасырның икенче яртысында Болгарстанның төп җирләренә, Кама аръягына Алтын Урда күчмәннәре һәм урыс басмачылары еш һөҗүм итеп, халыкны талап китәләр. Шул сәбәпле андагы халык тынычрак урынга, Каманың уң ягына, Мишә һәм Казансу елгалары бассейнына күчеп утыра. Бу вакытта инде Казан шәһәре көчәйгән, сәяси яктан әмирлек башкаласы була. Биредә дә, нәкъ Болгардагы кебек язылып кабер ташлары куелган. Шул уңайдан Урта Кабан күленең сул ягында, тау өстендә табылган кабер ташы текстын күчереп китерәбез. Архиерей дачасында табылган, хәзерге вакытта Татарстан милли музеенда куелган әлеге ташның язуы, татарчага әйләндергәч, түбәндәгечә була.

«Ул (Аллаһы Тәгалә) исән һәм үлмәс. Барча яшәүчеләр үләрләр. Бу урында бөек һәм мөхтәрәм хөкемдар, хөкемдарларның ярдәмчесе, хөрмәтле әмир... шәүкәтле... шәрифле һәм бөек, байрак...

шәүкәткә... ике данга... ыругының һәм иманның даны, дөнья хуҗаларының күләгәсе Мир Мәхмут улы Хәсән бәк кабере торыр».

Күп урыннары бозылган булганлыктан, 3 метр ярым биеклегендәге бу ташның куелу вакытын Ш. Мәрҗани ачыклый алмаган. Ләкин башка ташлар белән чагыштырып һәм тикшереп, белгечләр аны XIII гасыр ахрында куелган булырга тиеш, диләр. Димәк, бу — шул вакытта ук инде Казанның үзенең әмире-хөкемдары булган, ягъни Казан дәүләте яшәгән дигән сүз. Бу бер дә гаҗәп түгел, чөнки Болгар дәүләтендә феодал таркаулык монголларга кадәр үк башланган иде. Мисал өчен Ашлы әмирлеген күрсәтергә мөмкин ; 1220 елда урыслар Иделнең уң ягына урнашкан Ашлы әмирлегенә (кенәзлеккә) һөҗүм итәләр.. Кальганы җимергән вакытта аның әмире икенче як капкадан үзенең тән сакчылары белән качып котыла. Казан әмирлеге турында бераз вакыттан соң урыс елъязмалары да язалар. Мәсәлән, 1370 нче елларда Казанда Хәсән дигән әмир хакимлек иткән. Аңа каршы урыс гаскәрләре Алтын Урда фатихасы белән һөҗүм итеп килгәннәр. Димәк, Казан дәүләте ул вакытта ук Алтын Урдадан да, урыслардан да мөстәкыйль булган. Бөек Болгар җиренең феодал таркаулык кичерүен барлык галимнәр дә таныйлар, төрле әмирлекләр (кенәзлекләр) булуы турында язалар. Феодал таркаулык дәүләтнең ваграк әмирлекләргә бүленүе җәмгыятьнең алга китүеннән, җирле җитештерү көчләренең үсүеннән килеп чыккан күренеш. Шуңа күрә аңа тискәре караш дөрес булып бетмәс, һәр үсешнең үз үзенчәлекләре, үз вакыты бар.

Казан ханлыгы заманыннан калган кабер ташлары нигездә хәзерге Татарстан республикасы территориясендә таралган. Татарстаннан тыш болгар-татар ташлары Башкортстан, Удмурт республикалары, Ульян, Самара өлкәләре җирләрендә бар. Болгар дәүләте чорында ташлар күп булган. Кама аръягында, ягъни Болгарстанның төп җирендә, XIV гасырның икенче яртысында һәм XV гасырда аларның саны бик нык кими. Бу хәлне галимнәр XIV гасырның икенче яртысында Идел- Чулман Болгарстаны өстенә ябырылган афәтләрнең тискәре нәтиҗәсе дип аңлаталар. Чыннан да, 1361 елда Алтын Урда әмире Булат- Тимер бөтен Урта Идел буен харап итеп Болгар илен яулап ала һәм биредә үз хакимиятен урнаштыра. Аннан соң Новгород елга юлбасарлары (урыс ушкуйниклары) туктаусыз һөҗүм итеп тора башлый. Алардан калышмыйча, Мәскәү кенәзләре планлы рәвештә шул ук Кама аръягы өлкәсенә талау походлары оештыра. Нугай, башкорт һәм башка күчмә кабиләләр шунда күчеп йөреп туена башлый. Әлбәттә, мондый тыгызлыктан халык тынычрак урынга күчеп китә

башлый. Андый урын болгарларга күптән билгеле һәм таныш булган Мишә һәм Казансу буйлары, Каманың уң ягы була. Ләкин Кама аръягы (елганың сул як яры) бөтенләй бушап калган, анда халык Казан ханлыгы чорында яшәмәгән, авыллар да булмаган дигән сүз түгел. Хәлбуки, шулай дип әйтүчеләр дә бар. Кабер ташларының XIV- XV гасырларда кимүе бер Кама аръягына гына түгел, Кама алды территориясенә дә хас күренеш. Бу шул вакыттагы сәяси һәм социаль-экономик халәтнең үзгәрә баруы, тарихи үсеш процессының яңаруы белән аңлатыла. Бу бер яктан. Икенчедән, ташларның азаюын авылларның бетүе дип карау уйлап бетермәү аркасында туган ялгыш фикер. Моны шундый кыен шартларда ташларны ясарга мөрәҗәгать итүче хәлле кешеләрнең һәм таш ясаучы осталарның азаюы яки булмавы дип фараз кылу дөресрәк булыр. Болгарлар биеклеге 1,10, 2, 2,50, 3 метрлы калын ташларны Идел аркылы чыгып, Тау ягыннан (Иделнең уң ягыннан) алып кайта торган булганнар. Кама яр буйларыннан да тапканнардыр. Аны осталарның кярханәләренә (мастерскойларына) китереп «болай ясагыз, менә болай языгыз» дип сораганнар. Оста ташны үзенең махсус кораллары белән эшкәртә башлаган, аның аркасын, бордюрын һәм язу өчен урын әзерләгән. Әлбәттә, моңа байтак вакыт киткән. Мондый хезмәтне һәр кеше, һәр авыл башкара алмаган. Мондый кярханәләр һәм осталар Болгар шәһәреннән тыш кайбер башка шәһәрләрдә, зур авылларда гына булуы мөмкин. Ә алар югарыда әйтелгән сәбәпләр аркасында таланган, туздырылган да булуы бик мөмкин. Хәзерге көнгә, хәтерем ялгышмаса, 800 дән артык таш өйрәнелгән, шуларның 150 се Болгар шәһәрчегеннән табып алынган, 100 гә якыны Казан ханлыгы чорына карый.

Инде хәзер язмаларның эчтәлегенә килик. Без аларның теле турындагы мәсьәләләрне тел тарихы белгечләренә калдырып, кайбер гомум тарихи проблемаларга гына тукталырга булдык Проблемаларның эреләреннән түбәндәге сорауларга җавап кирәк: болгар эпитафияләре белән Казан ханлыгы заманыннан калган таш язулары арасында охшашлык, яисә охшашлык кына түгел, ә тәңгәл килүлек бармы, әгәр булса, ул кайчанга кадәр дәвам иткән? Бу сорауларга җавап нинди принципиаль проблеманы хәл итәргә мөмкинлек бирә?

1328 елгы Болгар ташы язмасы:

«хатын утыз биш яшендә
вафат булды, Тәңре рәхмәте берлә
сөендерсен, аминь.

Шәгъбан ае (унбишендә) һиҗридә(?)
йөти йөз егерме
сигездә ирде»

Казан ханлыгы заманындагы 1472 елгы язу:

«Тарих сигез йөз йитмиш йитедә рәҗәп ае
әүвәлендә ирде, шимбә көн ирде
Мөхәммәт углы Әюп дарелфәнадин
дарелбәкага рихләт кыйлды. Хак Тәгалә
рәхмәт кыйлгай. Инша Алла Тәгалә
Амин раббел галәмин»

1539- 1540 елгы таш язуы:

«Тарих тукыз йөз кырык алтыда Зөлхиҗҗә
аенда Корач углы Карачура дарелфәнадин
дарелбәкага рихләт»

Урыс хакимияте вакытында язылган 1594 елгы таш:

«Тарих мең ел узып икедә
зөлхиҗҗә аенда ирде Чапкын хатыны Җанай-Солтан
дарелфәнадин дарелбәкага рихләт кыйлды»

1695-1696 елгы таш язуы:

«Тарих мең дә йөздә йитедә ирде
Кутлу -бәй углы Солтан бәй билгесе, дога»

Мисаллар Һ.В. Йосыпов китабының кушымталар өлешендәге 22, 52, 63, 70, 74 нче таблицаларыннан алынды. Без бу мисаллардан гарәпчә язылган Алланы олылау, Корьән һәм пәйгамбәр сүзләрен, догаларны төшереп калдырдык. Ләкин алары да бер үк шәкелләр белән бирелгән: «Ул (Алла) исән, ул үлмәс» яки «Ул бар нәрсәдән югары» һәм шуның кебек гарәпчә башка әйтемнәр. Мондый мисалларны күпләп китерергә була.

Таблицалар һәм өстәп язылган башка язмалар бер нәрсә турында сөйли. Безнең телебез бик артык үзгәрмичә, болгар заманнарын ук килә. Икенче төрле әйткәндә, без болгар бабаларыбызның уллары һәм кызлары. Беркайдан да килмәгәнбез, шунда үз бабаларыбыз җирендә халык булып оешканбыз

1281 елдан 1361 елга кадәр булган һәм белгечләр болгар язмаларының икенче стиле дип атаган эпитафиядән бер мисал. 1332 елда

язылган ташта болай диелгән:

«Ул исән, ул үлмәс. Барлык яшәүчеләр үлерләр. Йосыф Хаҗи улы Хөсәен зиярәте. Рәхмәтуллаһы галәйһи. Дөньядан күчде тарих җиат җөз утыр икеш җал, рәҗәп».

Бу соңгы сүзләр чуашчаджан тәрҗемә кылганда, җиде йөз утыз икенче ел дигәнне аңлата. Гарәп һәм татар сүзләре белән катышкан чуаш ел саны, чуаш сүзләре турында бик күп яздылар, бәхәсләштеләр. Урыс миссионерлары Н.ИИльминский һәм Н.И.Ашмарин Ислам мәдәнияте белән көрәштә һәм православие динен фин-угор халыклары һәм чуашлар арасында тарату максатында әнә шул сүзләргә таяндылар, чуашларның бабалары болгарлар булган, ә татарлар Алтын Урдадан килгән килмешәк халык дип дау кузгаттылар. Аларга соңгы елларга кадәр чуаш галимнәре һәм кайбер башка тикшеренүчеләр иярде. Ләкин алар 1877 елда булып узган археологларның IV съездында чыгыш ясаган В.В. Радловтан башлап безнең көннәргә кадәр тиешле фәнни нигезләнгән каршылыкка дучар булдылар. Болгар- чуаш теориясе бик җитди рәвештә тәнкыйть уты астына М.З.Зәкиев һәм чуаш галиме Я.Ф. Кузьмин-Юманади бастырган «Волжские булгары и их потомки» (Казань, 1993) дигән китапта алынды. Андагы төп фикерләрнең берсе - бу ташларны язучылар турында. Чуаш сүзләре дә очраган ташларны мөселман динендәге чуашлар язганнар. Мөселман чуашлар төркеме Болгар дәүләтендә яшәгәннәр һәм акрынлап болгарлашкан, XIV насырның икенче яртысында алар инде тәмам болгарлашып беткән. Хәзерге чуашларны болгарларның варислары итеп карау хата булган кебек, ул мөселман-чуашларны да хәзерге чуашларның бабалары дип карап булмый. Чөнки чуаш халкы алар язып калдырган эпитафияләрне үзенеке итеп санамый да, өйрәнми дә. Татар халкында булган «безнең болгар бабаларыбыз» дигән аң аларда юк. Фәкать галим-голяма арасында асыл тарихи эзләрен тапмаудан аптырап татар халкы тарихын күчерү генә бар. Тагын бер фикер. Бу мөселман чуашлар төркеме болгарлар белән бергә борынгы Хәзәр җиреннән күчеп килгән булырга мөмкин. Хәзәр дәүләтендә төрки тел шундыерак булган дигән хәбәрләр бар.

Моңа өстәп шуны әйтәсе килә. Петр I фәрманы белән тәрҗемә ителгән язуларның күбесе монголларга кадәр язылган һәм шундый ук гарәпчә формулалар белән башлана(«Ул исән, ул үлмәс»). Тарих фәнендә вакытны билгеләү (датировка) мәсьәләсе бик мөһим һәм җитди эшләрдән санала. Тәрҗемә кәгазьләренең кырыенда «бу ташка 557 ел» («оному камню 557 лет») дип, һәм башка елларны күрсәткән

искәрмәләр бар. Әлеге ташның урысча тәрҗемәсендә анын куелу вакыты 619 ел дип күрсәтелгән. Милади буенча ул 1222 ел була. Әгәр искәрмәне 1722 елда К. Сөнчәләев язган булса, ташның куелу вакыты 1165 ел була. Бу иң борынгы, иң карт таш язуы булып чыга. Ләкин 1222 елга 557 не кушсак, 1779 нчы ел килеп чыга. Бу елда искәрмәләрне кем язган? 724 елгы таш язуына «бу язуга 452 ел» дигән искәрмә ясалган. Ташның елы безнеңчә 1324 була. Шуңа искәрмәдәге елны кушсак, 1776 ел була.

Казан адмиралтейство командиры Свечин губерна канцеляриясендә калган таш язуларының тәрҗемәләрен күчереп алган һәм бәлки ул язып куйгандыр. Чит ил эшләре архивыннан борынгы актлар Үзәк дәүләт архивына Свечин материалларын тапшыру әнә шул 1776-1779 елларда булгандыр ахры. Тагын бер гаҗәп нәрсә бар. 47 эпитафиянең 23 се 1226 елга карый. Бу елда нәрсә булды икән? Башка елларда бу кадәр үлем булмаган, бәлки нинди дә булса чир, эпидимия булгандыр, чөнки бу елда сугыш халәте күзәтелми. Ләкин мәсьәлә анда гына түгел. Бу эпитафияләр нинди булган: болгармы яки мөселман чуаш телендәме? Ф.С.Хәкимҗановның югарыда әйтеп кителгән китабыннан бер мисал китерик.

«Ул исән, Ул үлмәс. Булартай бине Булашмак бәк зиярәте торыр. Илаһым, аны җәннәт сыйлары белән шатландыр. Рәҗәп ахрында тарих йөти йөз йөгерме түрттә» Бу һәм башка борынгы язулар чиста болгарча язылган. Г. Әхмәров тарафыннан табылып күчерелгән 1244 ел язмасы да болгарча язылган булган. Ләкин чуаш телле язмаларның бары тик 80 еллап кына, аерым бер чикләнгән чорда гына язылып калуын ничек аңларга? Ихтимал ки, моңа төрле тарихи вакыйгалар сәбәп булгандыр, ләкин ниндиләр, ни өчен? Шулай итеп, бу өлкәдә эшлисе эшләр байтак әле. Гомумән, кабер ташы язмаларын өйрәнү эше дәвам ителергә тиеш.

Аларда сәяси һәм сугыш хәлләре мотивлары да күренә. Мәсәлән: 1382 елда Габделҗаббар улы кемнеңдер килү вакытында шәһит китә (Туктамыш хан һөҗүме түгелме?); 1530 елда Мөхәммәт - шах бәк углы Мөхәммәт Гали бәк кяфер кулыннан шәһит (бу инде шул елдагы Мәскәү -Казан сугышы корбаны); 1541 елда Кунак- Хуҗабай углы Җиан-хуҗа каядыр барганда «кяфер кулындин шәһит булды» һәм башкалар. Әмир, бәк, хуҗа, хаҗи кебек термин- атамалар социаль тормыш турында сөйлиләр. Алар турында сүзне озайтмыйча, укучылар игътибарын Һ.В.Йосыпов һәм Ф.С.Хәкимҗанов китапларына юнәлтү белән чикләнәбез. Ләкин әле тагын бер җитди мәсьәлә бар.

Кабер ташлары үзләренең борынгы язмалары белән төрле авыл-

ларның «иске зиярәт» яки «иске каберлек» дип аталган каберлекләрендә саклана. Ул каберлекләр һәм ташлар шушы авыл кешеләренең бабаларымы, ягъни бу авыл әнә шул борынгы Болгар -Казан заманнарыннан бирле яшиме?

Үз вакытында Каюм Насыйри Зөя өязе авылларын һәм ул авыллардагы кабер ташы язмаларын өйрәнеп, байтак авылларның бик борынгыдан, болгар заманнарыннан бирле яшәгәнлекләрен язып калдырган иде. (Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр. Ике томда. Икенче том, Казан, 1975) Яшьрәк чагымда мин галимнең ике томлыгын басмага әзерләү уңаеннан Каюм бабай эзләреннән ул авылларда булган идем. Ләкин башка мәшәкатьләр аркасындамы, яшьлегем сәбәплеме, ул ташларны өйрәнергә вакыт тапмадым. Каюм Насыйри хезмәтеннән мисаллар китерик.. Әҗәли авылы каберлегендәге ташта «тарих сикез йөз сиксән алтыда Чура углы Дулгәнур фани сарайдин бәка дарины мәкам итти». Бу дата безнеңчә 1481-1482 елларга туры килә, ягъни авылны Казан ханлыгы чорына нисбәт итәргә нигез бар. Ләкин К. Насыйри бу авылны тагын да борынгылата. «Шул тирәдә бер якын зиярәт бар, мукшы каберлеге дип атыйлар икән. Ул зиярәткә хәзердә дә дога кылырга баралар, барып Корьән укыйлар икән. Ул зиярәттә изгеләрдән бәгъзе адәмнәр бар, имеш. Ул авыл мөселман булган икән. Ул мукшы авылы Болгар таркалмастан элгәре һәм бар икән».

Һәм тагын, «Ул Хаҗ Гали исемле адәм алты кеше белән Болгардан килеп, авыл булып утырганнар... Хаҗ Галине кыскартып Аҗәли дип йөрткәннәр... Әҗәли авылы соңрак Мамадыш - Акил авылы белән кушылган», дип яза һәм бик борынгы авыл, ди. Мамадыш авылы имамнарының бабалары Биләр шәһәреннән күчеп килеп утырган. Гәйнулла исемле мөәзиннең унберенче бабасы шуннан килгән икән. Әҗәли авылы каберлегеннән күчереп алган таш язуы Һ.В.Йосыпов китабында да нәкъ Каюм Насыйри укыган рәвештә китерелгән. Танай авылы каберлегендәге ташта «тарих тукуз йөз иллектә»; ««Тарих тукуз йөз кырык өченчедә» (1543, 1536 еллар) дигән сүзләр шул елларда бу авылларның булуы турында сөйлиләр, ди галим.

Мулла Иле авылы бик кадимге авылдыр. Таш язуында ошбу сүзләр: 1199 (1784) сәнә мөхәррәм ае, тәүфикъ Алладан, дөнья һәм анда булган нәрсәләр бетәчәк. Бу урында Габделхаликъ бине Габделбакый бине мулла Сәет бине Касыйм бине Ишмөхәммәт хафиз бине Ижбулат бине Ирежмәс бине мулла Теләш бине Шәехби бине Тәмти-Хытай Әлболгари күмелгән, дип авылның искелеген шәҗәрә ярдәме белән дә куәтли. Чыннан да 1784 елгы шәҗәрәдән ун буын вакытын чигерсәк (10*25=250)

1534 ел килеп чыга. Мондый мисалларны тагын да китерергә мөмкин.

Шунысы әһәмиятле, К.Насыйри авылларның башлангыч тарихын зиярәтләрдәге таш язулары белән бәйли һәм аны нәсел язулары белән ныгыта, шул авыл кешеләренең нәселдән нәселгә күчеп шунда яшәгәнлекләрен исбатлый. Моны кире кагу өчен безнең дәлилләребез юк.

Шул ук фикерне Һ.В.Йосыпов та әйтә. Аның югарыда күрсәтелгән китабыннан бер өзек китерәбез: XIV гасыр эпиграфикасының XVI гасыр язулары белән бәйләнеше бер үк авыл каберлегендә шул гасырлардан калган (XIV, XV, XVI һәм XVII) ташларның булуында күренә, алар байтак авылларда бар (Саба районының Измә, Теләче районының Нырсы, Кибәхуҗа, Зеленодол районының Азелей, Арча районының Кишет һәм башка авыл каберлекләрендә. Моны ассызыклап әйтергә кирәк, дип дәвам итә галим, чөнки элек заманда авыл каберлекләренә үз кешеләреннән башкаларны, читтән килгән адәмнәрне, мөселман булсалар да, җирләмәгәннәр, аларны үлә калсалар читтәрәк күмгәннәр. Шулай итеп үз каберлекләрен бабаларының урыны изге дип, гасырлар буена саклаганнар. Димәк, кайбер авыллар болгар заманнарыннан бирле яшиләр.

Казан ханлыгы чорыннан калган таш язулар Болгар дәүләте вакытындагыларга караганда пөхтәрәк, матуррак эшләнгән диләр. Бу факт мондый төр һөнәрчелекнең бер кадәр алга китүен, югары баскычка күтәрелүен күрсәтә. Казанның үзендә табылган ташларның иң борынгысы XIII гасыр азагындагы Мир Мәхмут углы әмир Хәсәннеке. Ләкин аларның бик күбесе инде югалган һәм харап ителгән. Урыслар Казан ханлыгын җимергәч, татарлар кайбер кабер ташларын читләргә калдырмас өчен үзләре дә алып китә торган булганнар. Мәсәлән, элек әмирлек үзәге булган Җүкәтау каберлегеннән, урысларга калмасын дип, берничә ташны татарлар алып китү очрагы теркәп калдырылган. (С.М.Шпилевский)

Кабер ташларына язу язып кую гамәленең әле тукталганы юк, халкыбыз үлгәннәрнең хәтерен саклап ул эшне һаман да дәвам итә.

Авыл тарихларын барлаганда урыс язмаларына гына таянып эш итү үзен акламый. Мәсәлән, Зөя өязенең Мулла Иле авылы Казан ханлыгы чорында ук яшәгән. Ә урыс язмасында ул бары тик 1565 елда гына күренә. Мондый мисалларны күбрәк тә китереп булыр иде.

## *Шәҗәрәләр*

Татар шәҗәрәләре, югарыда күргәнебезчә, кайбер кабер ташларында да язылган. Аларны беренче «басмалар» дип тә атарга мөмкиндер, чөнки кәгазьдә булмасалар да, алар һәр кеше өчен ачык, теләгән

кеше укый алырлык хәлдә. Кабер ташларының күбесендә күмелгән кешенең үзе һәм аның атасы телгә алына. Мәсәлән, «Тарих сикез йөз икедә... Ибраһим углы Исхак, утыз алты яшендә иде...» Бусы да мөһим, чөнки гадәт буенча һәр буынга 25 ел вакыт биргәндә дә, без таш куелган заманнан элгәресен дә күзалларга мөмкинлек алабыз (1399-25 =1374). Казан ханлыгы чорыннан тагын бер мисал: «Тарих сикез йөз йөтмеш йөтидә, рәҗәп ае әүвәлендә ирде, шинбә көн ирде. Мөхәммәт углы Әюп...» Ә бит аларда берничә буынны күрсәткәннәре дә бар. Ш.Мәрҗани Кәче авылы мулласы Юныс бине Иванайның шәҗәрәсен каберлектәге Иванай хафизның таш язуы белән бәйләп китерә. Бу шәҗәрәдә буыннар саны 9, ә кабер ташы 1689 елда куелган. Димәк, 1689 дан 9* 25 =225 не алсак, 1464 нче ел килеп чыга. Юныс мулланың ерак бабасы Әбүзәр әл Кәчеви әнә шул елларда, Казан ханлыгы заманында яшәгән кеше була. Нәсел- нәсәбе, таш язуы шул каберлектә булгач, Кәче авылы да һич югы шул вакыттан бирле яшәп киләдер. Кайбер таш язмалар безнең хәзерге авылларның тарихын болгар заманнарына ук алып барып җиткерә. Бусы да бик артык гаҗәп түгел. Авыллар читләр һөҗүм иткән вакытларда яндырылган, җимерелеп кырылган. Ләкин, археология фәне күрсәткәнчә, качып киткән, таралган кешеләр 10-15 елдан яңадан кире кайтып, шул ук туздырылган авылның үз урынында, йә булмаса янәшәсендә яңа өйләр салып авылларын торгызган.

Без Аксубай районы Шәрбән авылының тарихи урыннарын карап йөргәндә урамнарда һәм бәрәнге бакчаларында байтак чүлмәк кыйпылчыкларына тап булдык. Археолог Фаяз Хуҗин бусы XII гасыр чүлмәгенеке, монысы XI гасыр чүлмәк ватыгы, дип билгеләп барды. Соңыннан шундый табылдыклардан күргәзмә дә оештырылды. Бу авыл болгар авылы өстендә утыра һәм бәлки үзенең яшәвен бер вакытта да өзмәгәндер. Менә тагын хәзерге Нурлат районына кергән Иске Әлмәт һәм Яңа Әлмәт авыллары. Аларны бер авыл дип тә әйтергә мөмкин, чөнки араларында инде хәзер кечерәеп бара торган елгачык кына бар. Әнә шул Мораса һәм аңа кушыла торган Гәрәй елгалары буенда, авылга якын гына Болгарның ике шәһәрчек калдыклары XIX гасырда ук (С.Мельников, С.М.Шпилевский) тарихи әдәбиятка кереп калган. Аталган авыллар шул шәһәрчекләр заманыннан калган дип әйтергә дәлилләр җитми, ләкин монда нинди дә булса бәйлелек булуы бик мөмкин. Мондый мәсьләләр кузгатылганда бик сак, уйлап эш итәргә кирәк, минем мондый хәлгә дә очраганым булды. Бер авылда миннән «ничек уйлыйсыз, безнең авылга ничә яшь?» дип сорадылар. Мин 1650 елларда Кама

аръягы линиясен төзиләр, димәк авылларга 330 еллар була, дидем. Абзыем арты белән борылды да, кулын селтәп «беләсең, пычагым» дигәндәй китеп барды. Татар халкының шәҗәрәләрен өйрәнү, аларны бастырып дөньяга чыгару атаклы галимнәребез Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Р.Фәхретдиннәрдән башланып, бүгенгә кадәр дәвам итә. Соңгы елларда шәҗәрәләргә анализ ясап, аларның гомуми тарихи чыганак буларак әһәмиятен, теоретик нигезләрен күрсәтеп М.Г.Госманов һәм М.И.Әхмәтҗанов бик зур эш башкардылар. Миркасыйм Госмановның «Татарские исторические источники XVII —XVIII вв.» (Казань, 1972), Марсель Әхмәтҗановның «Татарские шеджере» (Казань, 1991) китаплары бик бай тарихи мәгълумат бирә, шәҗәрәләрне өйрәнү бурычларын куя. Без шәҗәрәләрне өйрәнү тарихына тукталмыйбыз, чөнки бу мәсьәлә югарыда телгә алынган китапларда яктыртылган инде. Шулай ук аларны тикшерергә дә алынмыйбыз. Казан ханлыгы чорында язылган һәм безгә кадәр килеп җиткән шәҗәрәләр юк, табылмаган. Шуның өчен бу турыда сөйләшү мөмкин түгел. Бер нәрсәне искәртәсе килә. Хәзерге вакытта бик күпләр атасыннан кала бабасын да белми. Фамилиясе аркылы кайберәүләр бабасын беләдер. Үзеңнең нәсел - нәсәбеңне белмәү, бабаларыңның рухын сакламау аяныч күренеш ул. Элек «җиде яисә тугыз бабаңны бел» дип эш иткәннәр, бала тәрбияләгәннәр. Үзеңнең нәселеңне белмәү халкыңнан аерылуга алып бара Милләтемне кайгыртам дисәң, үзеңнең нәсел - нәсәбеңне хөрмәтлә, бабаларыңны бел, аларның исемлеген генә булса да язып бар һәм киләчәк буынга, балаларыңа калдыр. Кыскасы, шәҗәрәләр төзү кабер ташына язып та, кәгазьгә төркәп тә дәвам итсен иде.

Буш сүз булмасын дип, «үзеңнең бабаларыңны бнләсеңме соң», дип сораучылар булса, үз шәҗәребезне китерәбез. Аның бер варианты М.Әхмәтҗанов китабында урын алган иде.

1. Галишаһ - Галиш - Алиш = Тау ягындагы Шунгаты авылында XV11 йөз урталарында
яшәгән. Хәзерге Апас районы
Шонгуты урыс авылы.

2. Әлмөхәммәт яки Әлмәтулла
булса кирәк, шәҗәрәдә Әлмәт = Шунгатыдан Мораса
елгасына Гәрәй суы кушылган
җиргә килеп утыра. Хәзерге
Нурлат районы Иске Әлмәт
авылы.

3. Сөрмөхәммәт, Сөрмәт = Корьән хафиз булган дигән
дип йөрткәннәр.  Истәлек сакланган.

4. Ибраһим хәзрәт = Сөрмәт һәм Ибраһим Иске
Әлмәттә яшәгәннәр. Ибраһим
1690 елда туган.

5. Җәгъфәр хәзрәт = Мораса елгасының уң ягына
чыгып утырган. Яңа Әлмәт
дип аталган яңа авыл бар-
лыкка килгән. Китаплар авто-
ры. Бер китабының ахырында
Әлмәтне «җәдиди авыл» дип
атый. Яшәү еллары 1729-1790.

6. Гөбәйдулла ишан = Кизләү авылында яши. Вафаты
1823 ел. Балалары:
Нигмәтулла ишан Әлмәти,
Дамелла Рәхмәтулла Кизләви,
Дамелла Хәбибулла Кәкре-Тау
авылы мулласы, 1878 елда вафат.

7. Нигмәтулла ишан Әлмәти = Тирә якта дан тотып 1853 елда
вафат. Язулы ташы белән
кабере Яңа Әлмәт авылының
Тау башы зиярәтендә.
Ш. Мәрҗани, «безнең хатыныбыз мәрхумә Биби- Фатыйма бинте
Габденнасыйр ахун,
анасы соңыннан әлеге Нигмәтулла
никахында булганлыктан, аның үги кызы иде»,
дип язып калдырган.

8. Хәйрулла хәзрәт = атасы урынында калып Яңа Әлмәтнең
имам, хатыйп һәм мөдәррисе булып тора.
1888 елда үлә, атасы янында күмелгән.
Нигмәтулланың икенче углы Гатаулла
Иске Әлмәт мулласы була. Гатаулла
углы Нурулла Абдулла Алишның бабасы
Киек авылына китеп мулла була.
Сөнгәтулла дигән углы Мораса авылы
мулласы, аның баласы Зәки мулла
Казанда яшәде.

9. Мирхәйдәрҗан мулла = Яңа Әлмәттә, хәтерем ялгышмаса, 1912 елда үлгән.

10. Мөхәммәт Хатыйп = 1936 елга кадәр булса кирәк Яңа Әлмәттә мулла булып торды, аннан соң үз һөнәрләре белән дөнья көтте. Яшәү еллары 1870 - 1945. Аның беренче хатыны Фатыйма абыстай Гаяз Исхакиның анасы Камәрия абыстайның сеңелесе була. Беренче улы Габделхәй, Мораса авылында укытучы булып эшләгәндә, 1921 елда революционер буларак бандитлар тарафыннан атып үтерелә. Шул авыл мәйданында кабере саклана.

Мин, Сәлам Хатыйп улы, атамның икенче хатыны Нурвисальдән 1929 елда туганмын. Улларым Булат, Айрат һәм Самат бар. Аларга шәҗәрәбезне дәвәм итәргә әйтелгән.

Болардан тыш, ерак бабалар турында төрле чыганакларда башка-чарак искәрмәләр дә бар. В.В. Вельяминов - Зернов үзенең атаклы китабында (Т.3, с.237) Касим татарлары арасында XVII гасыр урта-сындагы Алиш углы Әлмәт морзаны күрсәтеп уза. Бер вакыт Мордва республикасыннан килгән галимнәр «без сине үзебезнең энциклопе-диягә кертәбез, сезнең Алиш мордва морзасы булган» дип тә әйттеләр. Төркиядә Фазыл Алишев яши. Казанга берничә ел элек килгән булган, ләкин очраша алмыйча калдым. Бу хакта Мөселман календаренең 1999 ел чыгарылышында 17 август көненә багышлан-ган битеннән укып кына белдем. Аның атасы «Хәсән Алишев Мор-довия районы Татар Юнәсе (Юньск) авылында туган икән. Алар гаи-ләсенә Гаяз Исхаки килеп - кереп йөргән. Алишевлар нәселен бик хөрмәт итә иде, дип сөйләгән. Югарыда китерелгән шәҗәрәнең күп тармак- ботаклары бар. Алишевлар Кавказ, Урта Азия, Үзәк Рәсәй җирләрендә яшәгәннәр һәм яшиләр. Аларның барысынада тукталып булмый, укучылар шаять гафу итәрләр.

Шулай итеп, кабер таш язулары һәм шәҗәрәләр тарихыбызның җитди чыганаклары булып торалар. Әгәр аларны җыеп тупланмалар эшләнсә, аларга югарыдагы кебек кыскача аңлатмалар бирелеп ба-рылса, татар халкы тарихының гүзәл бер күренеше булыр иде.

«Болгар -татар эпиграфикасы буенча комиссиянең эш йомгакла-ры» дигән өч томлык альбом 67 таш язуын берләштергән һәм аларга аңлатмалар бирелгән килеш Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты архивында саклана. Аларны, Һ.В. Йосыпов

һәм башкалар матбугатка чыгарганнарны бергә җыеп тупланма бастырылса, халыкка җиткерелсә, тарихчыларга, авыл тарихлары, үз нәселләре белән кызыксынучыларга зур бер бүләк булыр иде. Шундый ук хәл шәҗәрәләр белән дә. Күптән түгел Мәгариф музеенда шәҗәрәләр күргәзмәсе эшләде. Аңа кадәр, берничә ел элек Казан милли мәдәният үзәгендә шундый ук күргәзмә үткәрелгән иде. Аларның барсын бергә туплап чыгарылса күп мәгълумат алыр идек.

***Файдаланылган хезмәтләр***


1. Юсупов Г.В. Введение в булгаро- татарскую эпиграфику. — М., Л.- 1960.
2. Усманов М.А. Татарские исторические источники XVII - XVIII вв. - Казань, 1972.
3. Ахметзянов М. Татарские шеджере.- Казань, 1991.
4. Смирнов А.П. Волжские булгары.- М.,1951.
5. Вельяминов- Зернов В.В. Исследования о косимовских царях и царевичах Тт. 1-III,-СПб, 1863-1866.
6. Рычков Н.П. Журнал или дневные записки путешествия по разным провинциям Российского государства в 1769 и 1770 гг. - СПб, 1770.
7. Хакимзянов Ф.С. Язык эпитафии Волжских булгар. - М.,1978.
8. Шпилевский С.М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии. - Казань, 1877.
9. Акты исторические и юридические и древние царские грамоты Казанской и др. соседних губергий. Собрал С. Мельников. - Т. 1- Казань, 1859.
10. Закиев М.З., Кузьмин- Юманади Я.Ф. Волжские булгары и их потомки. - Казань, 1993.
11. Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр. Икенче том.- Казан, 1975.
12. Шиһабетдин Мәрҗани. Мөстәфадель- әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. - Казан, 1989.
13. Мөселман календаре. — Казан, 1999.

## 3. Халык авыз иҗаты

Халкыбызның авыз иҗаты шул кадәр бай, күпкырлы һәм төрле жанрларга ия ки, мин аларның кайсыннан башларга икән дип уйга калдым. Әкиятләрдәнме, мәзәкләрдәнме, җырданмы, әллә тарихи риваятләрдәнме, дастаннарданмы, йә булмаса башкаларданмы? Ләкин бит аларның һәрберсендә тарихилык бар. «Сүз», аның артыннан тагын «сүз» һәм сүз диләр. Ә сүзгә кадәр кеше берни дә дәшмәгәнме? Бәлки кеше башта ниндидер авазлар чыгарган, моңланган, нәрсәдер көйләгәндер. Бала елап туган кебек, кешелек тә бәлки аваз биреп, яхшымы —начармы көй белән сүзгә күчә companyгандыр. Шулай булса җырлардан башлыйк әле.

Әлбәттә, борын- борын заманнардагы җырларга барып җитә дә алмыйм, һәм моңа биредә ихтыяҗ да юк. Мин беренче чиратта Казан дәүләте чорындагы җырларга, аның да тарихи яңгыраш алганнарына тукталырга тиеш. Ләкин иң әүвәл бер искәрмә ясарга кирәк. Тарихчы өчен нинди дә булса бер әсәрнең кай вакытта килеп чыгуы бик әһәмиятле. Язылу вакыты бик соң булуы мөмкин, авыз иҗаты әсәрләре телдән сөйләнеп кенә таралган. Тарихи вакыйга ул әсәрдән, яисә аның язылу вакытыннан элегрәк булырга, яки аның үз вакытында да булырга мөмкин. Әсәрнең туу вакытын күбрәк аның эчтәлеге буенча билгелиләр, бугай. Мәсәлән, болгар җәмгыяте чорында булган вакыйгаларның кайберләре Казан дәүләте заманындагы авыз иҗатында да туарга бик мөмкин. Әмма әсәрләрнең вакытын билгели торган алар турындагы риваятләрнең булуы да билгеле.

Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих (хәзер сәнгать) институты бастырып чыгарган күп томлы халык авыз иҗаты әсәрләренең «Тарихи һәм лирик җырлар» китабыннан мисаллар китерик. Китапта Казан ханлыгы чоры җырлары дип дүрт әсәр кителә. «Кунак бабай җыруы» дигәнендә бер карт мондый так-мак әйтә:

«Иделдә үтте тугыз хан,
Җаекта үтте сигез хан;
Шул ханнарның барысында
Күреп белгән карт мин.
Илне йоткан Туймас хан,
Юмарт булган Исәк хан;
Берсен сүгеп, берсен мактап
Күп җырлаган карт мин.
Туып үскән, суын эчкән,
Идел белән Җаегыма

Кайтарсагыз ни булган, дип
Башым игән карт мин.

Текстан күренгәнчә, җырчы үзенең туган илен Идел-Җаек, ягъни Идел-Урал елга буйлары дип билгели. Нинди ханнар үтүе, аларның исемнәрен ачыклау мөмкин булмаса да, авторның ханнарга мөнәсәбәте ачык, ул дөреслек һәм гаделлек яклы, явыз ханны тирги, гадел хөкемдарны мактый. «Кайтарсагыз» дигән сүздән аның әсирлеккә төшкән бер тоткын булуы ачыклана. Шуның белән бергә үзенең ватанын тирән яратуы, үз илен сагынуы да аңлашыла. Җыр турында аны 1916 елда язып алучы Хафиз Рәхмәтуллин мондый риваятне дә теркәп калдырган: Аксак Тимер Туктамыш ханны җиңгәч, бик күп кешене әсир итеп алган, алар арасында Кунак исемле бер болгар булган. Аксак Тимер «мине мактап җырла» дигәч, карт бабай әйткән:

Илне йоткан Туктамыш,
Мактаганым юк аны,
Син дә илне йоткан хан-
Мактый алмыйм мин сине.

Тимерләнг җырчының башын кистергән.

Җырчылар, җор сүзле акыннар, шагыйрьләр ул вакытта да күп булган.

«Ханәкә - солтан җыруы» да Казан дәүләте заманына карый, диләр. Ханәкә-солтан да Кунак бабай кебек әсирлеккә төшкән назлы бер хатын- кыз.

Кичәләр ятып төш күрдем,
Сараем башын кан алды,
Алты кызның эчендә
Ханәкә бикәм яу алды.

Бу өзектә сугыш, кырылыш авазы яңгырый. «Җиде кыз», «Унике кыз», «Кырык кыз» риваятләрен искә төшерә торган сүзләрдән башка, җыруның башка юлларында Ханәкә бикәмнең әсирлеккә төшүе, чит җирдә хөкем көтеп торуы күрсәтелә. Ул да туган илен сагына, юксына һәм ачыргалана. Күп галимнәр бу әсәрне «бәет» дип билгелиләр. Мин аны, җырлап та була бит, дип җырлар рәтенә керттем. Хаталансам, гафу итәрләр.

«Сөембикә китеп бара» һәм «Тоткын Сөембикә җыруы» дип аталган әсәрләрдә тарихта күп сөйләнгән, һәрберебезгә бик таныш булган Сөембикә-ханбикә турында, аның урыс әсирлегенә төшүе, тоткынлыкта җәфа чигүе хакында җырлана.

Идел ага яр кагып,
Уңга-сулга чайкалып;

Ут көймәсе китеп бара
Сөембикәне алып.

Аны утырткан көймә дә «ут көймәсе» икән. Аның әсирлеге дә зиндан эчендә икән!

Аһ, насыйб булырмы бәңа
Якты дөньяны күрү,
Әллә бу зиндан эчендә
Чыгармы газиз җаным.
Хәтфәдәй яшел улуб
Тора микән җир йөзе,
Яндырып бетердеме әллә
Аларны да дошманым.
Бакчаларда сандугачлар
Сайрый микән әле дә,
Әллә аларны да тоткын
Итте микән дошманым.

Бу юллар бик күп нәрсә сөйли. Халыкның уй-кичерешләре, моңсулануы гына түгел, Рәсәйне караңгы бер зиндан-төрмә дип, Сөембикәнең Рәсәйне дошманым дип санавы да биредә ачык чагылган. Сөембикә турында бу җырлар шул үз вакытында чыгарылган булса кирәк, ләкин бу темага соңрак та байтак җырлар, бәетләр иҗат ителгән.

Риваятләр дип сүз чыкты инде. Алар да халык телендә бик борынгыдан бирле яши дип санала, чөнки аларның кайберләре мифларга ук барып тоташа икән. Гадәтебезчә без Казан дәүләте чорына караган риваятләрне күзәтеп үтик. Бик күп риваятләр Казан шәһәренең кайда, ничек корылуы турында сөйли, алар арасында артык гади, төпле фикерле булмаганнары да бар. Кайберләре, Аксак Тимернең Болгарны туздырып ташлавы белән бәйләп, Казан каласын качып яки чигенеп килгән болгар кешеләре салган дип саный. Бер риваяттә Аксак Тимернең Болгар шәһәрләрен һәм авылларын яндырып, кешеләрен үтереп йөрүләренә ләгънәт укып сөйләгәннең соңында, үтерелгән Болгар ханы Габдулланың хатыны Бүләр шәһәре янында Тимерләнг каршысына ике баласы - Алтынбәк һәм Галимбәк белән чыгып, аңардан гафу үтенеп, Бүләрдән китәргә рөхсәт алуы турында сөйләнә. Алар Иске Казан каласын төзегәннәр, имеш. Габдулла хан нәселе Иске Казанда 104 ел хакимлек иткәннәр дә, аннан соң яңа Казанга күчеп, тагын 158 ел патшалык иткәннәр дип сөйли риваять. Бу саннар, риваятьләргә хас булганча, дөреслеккә туры килмиләр. Риваятьләрдә генә түгел, татарның иске язмаларында да вакыйгалар-

ның вакытын билгеләү фәнни дөреслеккә туры килми. Төгәл дата халык авыз иҗаты яки һәвәскәр тарих язмалары өчен хас нәрсә түгел, ә бары тик фәнни эзләнүләр, тикшеренүләр җимеше генә була ала.

Ләкин Габдулла ханның балалары —Алтынбәк белән Галимбәкнең— булуы башка ышанычлы чыганаклар белән исбат ителгәнгә күрә, риваятьләрдә аларның исемнәре китерелүе фәндә дөрес дип кабул ителә.

Икенче төр риваятьләр Казан каласының төзелүен елгага казан төшеп китүе, елгадан алтын балык тотылуы кебек нәрсәләр белән бәйләп аңлаталар. Бик борынгы легендаларга таянып, риваятьләр шулай ук шәһәр салынганчы бу урында бик күп еланнар булган икән, шәһәрнең нигезенә «кеше корбаны» салып калдыру кебек күп халыклар арасында таралган авыз иҗаты мотивларын да чагылдыра. Риваятьләрнең кызык кына урыннары да очрый. Әйтик, Казан шәһәренең нигезенә кеше корбаны түгел, эт мәете салып калдырганнар, имеш. Шуны ишеткәч, хан әйткән ди: «Димәк минем шәһәрем этләргә эләгер», дип. Бу инде риваятьнең шәһәр салынудан бик күп соң тууын, йә булмаса риваятькә өстәмә рәвештә килеп керүен күрсәтә.

Казан дәүләте яшәгән чорда түгел, ә урыслар тарафыннан яулап алынгач туган әсәрләр дә бар. Алар Казан ханлыгы чорын һәм аның урыслар тарафыннан җимерелүен яктырткангылыктан, кыскача гына моңа да туктальп китик. «Казан алынганы» дигән риваятьтә, мәсәлән, тәфсилле рәвештә шундый вакыйгалар сөйләнә. Казанның «голямалары вә мөдәррисләре вә һәм көтепханәләре күп иде вә талиплары (укучылары) күп иде». Казан ханы булып Ядькәр утырды, ләкин аның ир баласы булмау сәбәпле Казан кешеләре урыс әсирлегеннән аның кардәше Шаһгалине күп акча биреп йолып алдылар да, үлгән Ядькәр урынына хан итеп куйдылар. Шаһгали хан булганнан соң Казанда күп тынычсызлыклар вә фетнәләр була башлады. Ул урыслар белән дуслашып, татарларга зур хыянәтләр кыйлды. «Хазинәдәге дарыга су сиптерә» диделәр. Шуннан соң урыслар белән җиде ел сугыш булгандыр. Моңа кабер ташындагы язулар шаһит. Мисал өчен Чуел (Цивильск) өязенең Шәгали авылындагы кабер ташы язуында шундый сүзләр язылган: «Тугыз йөз кырык тугызда....Кужай углы кяфер тукышындин шәһит...» Моның тарихы 1549 нчы елларга туры килә, ди риваять. (дөресе 1542 ел) Халык арасында Казан өчен сугыш турында бәетләр дә сөйләнеп йөргән икән: «Каладин калая туплар атылды, сучсыздин сучлуя балалар катылды». Урыс патшасы каланы алырга әмәл таба алмагач, Җылан тавы катында җир астыннан канау казып, крепость астына дары куеп күтәрттергән. Казан алынгач, урыс кешеләрнең барчасын һәлак итте, мәдрәсәләрне яндыр-

ды, китап- корьәнне җыеп яндырды, йортларны вәйран итте. Кайберләре төрле якка качып котыла алды. Шәгали һәм Арча юлы белән чыгып китте. Чыгып киткәндә болай әйткән имеш:

Дус, дус дигәнем,
Дус түгел икәнсез.
Дус диябүк йөргәнем,
Бар да дошман икәнсез.
Әй, балалар, балалар,
Бездән елап калалар;
Бездин калган малларны
Кяферләр килеп алалар.

Бу риваятьне Каюм Насыйри халык телендә булган сөйләшүләрдән, мәсәлән, Наласа авылы картыннан язып алган. Әлбәттә, риваятьтә гадәттәгечә төрле ялгышлар бар. Ләкин төп вакыйга, Казанны урысларның сугышып, кешеләр үтереп, мәдәниятне җимереп алуны тасвирлау дөрес булып кала.

Шуның кебек риваятьләр тагын да бар. Урысларның хәйлә белән үгез тиресе зурлыгында гына җир сорап алулары, Шаһгали ханның мәкерлеге, Казан ханнарының исемлеген китерү кебек һәм төрле ялгыш даталар әйтүләр очрый.

Зөя каласын төзү турындагы риваятьтә (аны Каюм Насыйри халык теленнән язып алган) урыслар каланы башта Куҗамка һәм Исакау авыллары арасындагы ике тау өстенә салыргамы әллә, дип киңәшкәннәр, әмма аннары бу ике тауны тоташтыру өчен дамба салырга кирәк булачак, бу бик кыйммәткә төшәчәк дип, башка урын табулары турында сөйләнә. Бу урында бер яктан Зөя елгасы, икенче яктан бер инеш ага икән. Ул инеш—елгачыкта бик күп шүкә балыгы булганлыктан, аңа Щука дип исем кушканнар, диелә. Бу җирдә җимеш, алма бакчасы булган. Кала сала башлагач Казанның ерак булмаганын күргәннәр имеш. Казанлылар кала салганны күрмәсеннәр дип, Казан ягын бик зур киндер чаршау белән каплап куйганнар, ди. Казан ханы биек манара башыннан күзәтү трубасы белән карап ыгы—зыгыны күргән, ләкин берни дә эшли алмаган.

Аерым шәхесләр турында да риваятьләр сакланган. Шулардан берничәсен китерәбез. Сөембикә турында берничә төрле сөйләүләр булган. Берсе: Мәскәү патшасы гүзәл Сөембикәне төшендә күреп гашыйк булган, ди. Үзенә хатынлыкка сорап илчеләр җибәргән. Сөембикә риза булмагач, патша «алай булса, мин сине сугышып алам», дип сугыш ачкан. Җиде ел сугышканнар. Сөембикә дошманының җиңүен күргәч,

ире күмелгән мәчетнең манарасына менә дә аска ташлана. Шуннан соң хан мәчетен Сөембикә манарасы дип атый башлыйлар. Чынлыкта алай булмаганы билгеле, тик бер искәрмә бар. Халык авыз иҗатының берничә үрнәгендә «җиде ел» буена барган сугыш турында әйтелә. Кайдан алынган һәм нәрсә булган, нигә җиде ел? 1552 нче елдан җиде елны алсак, 1545 нче ел була. Тарихи вакыйгалар бу елда Мәскәү хөкүмәтенең зур гаскәр әзерләп Казан өстенә җибәрүен сөйли. Бу гаскәрне казанлылар көчле һөҗүм итеп куып җибәрәләр. Гамәлдә бу ел Мәскәүнең Казанны алу өчен сугыш башлавы була. Шуннан соң инде Мәскәү белән Казан арасында тыныч тормыш булмаган һәм капма каршы тору 1552 елга кадәр җиде ел дәвам иткән.

Кол Шәриф риваятендә болай язылган: Казанны урыслар яулап алганда кала эчендә сигез манаралы бер җәмигъ мәчет һәм «Таҗик ермагы» дип аталган мәхәлләдә янә бер мәчет вә мәдрәсә бар иде. Галимнәр, шул исәптән габбаси изгеләр вә галәви сәедләр күп иде. Аларның рәисе «изгеләр җитәкчесе» дип атказанган Шәрифкол исемлесе, ислам ханнары вә шәһәр халкы алдында газиз вә мөхтәрәм бер кеше иде. Русия кенәзләре Казан ханнарына илчеләр җибәреп хатлар күндергәндә, сәед Шәрифкол исеменә дә хатлар һәм бүләкләр җибәрәләр иде. Соңыннан, Казан өчен сугыш барганда, ул үзенең яраннарын вә иярченнәрен янына җыеп, мәдрәсә түбәсенә менеп урыслар белән бик каты сугышты. Алар барысыда шунда кырылдылар. Кол Шәрифне дә урыслар мәдрәсә түбәсеннән чәнчеп төшерделәр һәм ул шунда шәһит булды. Монда барысы да чынбарлыкка туры килә. Чөнки бу Ш. Мәрҗани хезмәтеннән алынган риваять. Бер генә искәрмә бар. Кол Шәриф билгеле булганча, шагыйрь, мәдәният, мәгариф һәм дин эшлеклесе, Казан ханлыгында зур абруйга һәм сәяси көчкә ия булган дипломат та. Ләкин кайберәүләр язганча, ул Мөхәммәт пәйгамбәр нәселеннән түгел. Сәедләр, соңрак ишаннар, үзләренең шәҗәрәләрен төзегәндә «без Мөхәммәт өммәте» дигән гыйбарәдән чыгып, Мөхәммәт пәйгамбәрдән башлап язганнар. Габбаси изгеләренең күп булуы да дөрес түгелдер.

Казанны яклап сугышу, изгеләр, Батман батыр һ.б. турындагы риваятьләргә тукталып тормасакта ярар. Тик шунысын әйтергә кирәк. Батман батыр риваятендә Казанны урыслар яулап алганның соңында барган халык сугышының (1552-1557 еллар) мотивлары яңгырый дияргә була.

Авыллар тарихына караган риваятьләр дә бик гыйбрәтле һәм кызыклы. Кабер ташлары турында язганда без бу хакта инде бераз әйткән идек. Бу бигрәктә Каюм Насыйри язып калдырган «Археоло-

гия материаллары. Зөя өязе авыллары буенча» дигән хезмәтеннән файдалануда күренде. Анда байтак риваятьләр дә китерелгән. Мәсьәлән, Әҗәли авылы риваятендә болай әйтелә:

«Бикмәмәт мулла риваять кыйладыр икән: шул тирәдә якын бер зиярәт бар, мукшы зиярәте дип атыйлар икән. Ул зиярәткә хәзердә дә дога кылырга баралар, барып корьән укыйлар икән. Ул зиярәттә изгеләрдән бәгъзе адәмнәр бар имеш. Ул авыл мөселман авылы булган икән. Ул мукшы авылы Болгар таркалмастан элгәре һәм бар икән. Әҗәлидә мулла булып торган адәмнәр чама белә 1626 нчы еллардан билгеле, ул вакытта анда Җәмид дигән кеше имам булган, аннан соң башкалар.

Мамадыш авылларының тарихи риваятьләре аларның бер кеше нәселеннән таралуы турында сөйли: хәзерге Мамадыш дигәннәрен Мамадыш Акил дип йөртәләр. Танай авылы — Тәүгилде Мамадыш булган, Салтыган авылы — Мамадыш Салтыган булган, хәзер Ышналы баш диләр. Йәнә Багаево дигән хәзерге урыс авылы Багай Мамадыш булган, Мамадыш Арсланово, Мамадыш Гордеево авыллары шул ук бер кеше балаларыннан икән. Бу кеше үзе Җәмит исемле булып, Болгарның Бүләр шәһәреннән килеп утырган, ди. Хәзерге вакытта Мамадышта мәэзин булып Гайнетдин дигән кеше яши, дип яза Каюм Насыйри, һәм аның унбер бабасын санап күрсәтә. Танай авылы имамнарын санап, аларның кабер ташларының 1536 - 1543 елларда куелганын әйтә. Риваять итәләр икән, бу җирләрдә ул заманда мөселманнар чуашлар белән бик катышканнар, чуаштан байтак халык мөселман булган. Чуашка кыз биргәннәр, чуаштан кыз алганнар. Риваятьтә болай дип тә әйтелгән. Җәмитнең бер баласы агасыннан сорый икән: кая барасың, дип. Агасы җавабында «мәмәдешләремә барам», ягъни туганнарым - имчәктәшләрем катына барам дигәне икән. Иске заманда Болгарда берәүнең «Мәмәдеш» дигән ләкабе булгандыр, дип өстәп куя галим.

Кавал авылына карата булган риваятьләр дә тарихи яктан кызыклы. «1301 нче елда,- дип яза М.Әхмәтҗанов,- Казан тарафыннан ике адәм сахрага чыгалар. Казан суы буйлап барганда, бер тармактан кергән суны күрәләр, бик чиста бер агымсу. Бу ике кеше әйтәләр: бу агым суның чыккан урынын карыйк, дип. Шул тармакка кереп китәләр, су бик яхшы ага. Бара- бара пустын (ягъни бушап калган авыл урыны) турысына җитәләр. Һаман шул су матур гына агып килә. Болар әйтәләр: моның чыккан урыны кайда икән? диләр. Су агымы буенча урман арасыннан китәләр. Килә- килә урыс Кавалы турысына җитәләр. Бу ике кешенең берсе Биктимер, икенчесе Бикбатыр исемле булган. Көннәрдән

бер көн, щул су агымы берлән килеп, шушы безнең Кәлимә тавы астына килеп җитәләр, суның чыккан урынын күрәләр. Сигез җирдә чишмә, тун җиңеннән аккан кебек агып тора. Моны күреп, бу ике кеше шак ката. Сулар бик һәйбәт, бик зур урман арасы. Суның һәйбәтлеген күреп кайтып китәләр дә, күргәннәрен башкаларга сөйлиләр. Йәнә дүрт кеше булып, шул ук урман арасыннан су агымы буенча киләләр. Сөйләшәләр: Без монда йорт салыйк, диләр. Әүвәл урман кисә башлыйлар, йортлар салмак булалар. Көннәрдән бер көн, дүртесенә дүрт йорт җиткереп, гаиләләрен алып киләләр. Бакчалар ясыйлар, яшелчәләр утырталар, урман төпләп чәчү җире ясыйлар. Һәм иген чәчә башлыйлар. Бу кешеләр бик зур урман арасына кереп утырган булалар. Бу урманда аюлар, пошилар, башка күп төрле җанварлар булган. Аюлар белән Бикбатыр бабай көрәш кыйлган һәм ул җиңеп чыккан. Шул урманнарны кисеп һәм төпләп, йортлар, өйләр төзеп, җир ясап һәм иген чәчеп, авыл ясый башлаганнар. Бу дүрт гаиләнең балалары күп булган, аларны башка чыгарып, авыл зурая башлаган.

Көннәрдән бер көнне җыелышып-сөйләшеп утырганда әйтәләр икән: Без бу авылга бер исем кушыйк, дип. Биктимер бабай белән Бикбатыр бабай әйткәннәр, «бу авылга исемне без болай кушабыз - без су агымын күреп килдек. Куып килгән өчен без моны Куал- Кавал дип әйтәбез. Биктимер һәм Бикбатыр бабайлар авылга «Кавал» дип исем куйдылар, шул заманнан «Кавал» булып китте. Шушы дүрт кешедән авыл зураеп калды. Монда әйләнә - тирә авыллар юк иде. Берничә еллар үткәч, башка авыллар да була башлады. Шул дүрт кешедән балалар булып, балаларының балалары булып, һәркайсы башка чыгып авыл зурайды. Бөтенләй кара урманга килеп утырган авыл булган бу Кавал.

Бу риваятьне мин авылларның ни рәвешле төзелүен бабайларыбызның ничек аңлатуын күрсәтү өчен китердем. Бик күп риваятьләр авылларның урман, хәтта карурман эчендә төзелүен, кешеләрнең агачларны кисеп чәчүлек җирләр ясауларын һәм өйләр төзеп утыруын сөйли. Шул ук вакытта аларның кайберләре бу авылга кешеләрнең кайдан килеп утыруларын да әйтә, ягъни җирләрнең урманнан гына тормаганлыгын, халыкның яшәгәнлеген күрсәтә. Риваятьләрнең тагын бер үзенчәлеге шунда - алар авылларның барлыкка килү вакытын билгеләргә тырыша. Аларның күбесендә йә өч йөз, йә дүрт йөз дигән саннар һәм югарыда күрсәтелгән кебек төгәл даталар да очрый. Әлбәттә, күбесе хакыйкәткә туры килми, ләкин аларны кабер ташы һәм башка ышанычлы язмалар белән чагыштырып карарга һәм шуның белән дөреслекне табарга мөмкин.

Авыллар тарихына караган йөзгә якын риваятьләрдән башка тагын топонимика, көнкүреш, аерым шәхесләр хакында һәм башка төрдәге язмалар һәм легендалар байтак җыелган. Аларның килеп чыгышы, мөгаен, ерак заманнардан киләдер, ә кайберләре соңрак тугандыр. Шунысы бар - риваятьләр һәм легендалар бик соң, XIX-XX гасырларда гына төрле кешеләрдән язып алынган. Алар күп томлы «Татар халык иҗаты» басмасының «Риваятьләр һәм легендалар» китабында тупланып бирелгән (Казан, 1987). Шулай булса да, аларның байтагында тарихи күренешләр, Казан ханлыгына хас вакыйгалар чагылган. Мәсьәлән, аларда Казанның урыслар тарафыннан яулап алыну, халыкның тормыш көнкүреше, аның патша - ханнарга мөнәсәбәте, каршылыклар, баш күтәрүләр һәм башкалар хакында мөһим мәгълуматлар бар.

Татар халык иҗатының «Дастаннар» китабында китерелгән әсәрләр дә бик әһәмиятле. Герой шагыйрь Муса Җәлил язган «Алтынчәч» операсының нигезе булган «Җик Мәргән» дастаны һәм Алтынчәч риваяте дә, минемчә, Казан ханлыгы чорында туган. Аларда монгол яуларының җирле төрки ыругларын, йә булмаса кабиләләрен кыру, җимерү күренешләре тасвирлана. Мин алар башка шундый афәткә багышлап чыгарылган, дип әйтә алмыйм.

Чөнки дастанда теркәлгән Чулман- Җаек буйларында барган көрәш бары тик монгол яуларына каршы көрәшне генә аңлата. Казан ханнары бу урыннарда кабиләләрне кырып йөрмәгән. Бу бер. Икенчедән, дастанда әйтелгән Казан ханының Җик Мәргәнгә һөҗүм итүе соңрак килеп кергән «ачыш» икәнлеге ап-ачык ярылып ята. Ясак түләүдән баш тарту очраклары, каршылыклар, әлбәттә, булган. Ләкин Казан ханнарының башкортларга каршы һөҗүме бер факт белән дә расланмый. Монда халык иҗатына хас булган алымнарның чагылышы урын алган, ә «дань» сүзенең килеп керүе дастанның соңрак тагын да баетылуы турында сөйли. Алтынчәч турындагы риваятьнең дастанга ул вакытта әле кушылмавы да аңлашыла, халык авыз иҗаты ул югарылыкка әле күтәрелеп җитмәгән, аның өчен лирик шагыйрьнең көче һәм таланты кирәк булган.

Тагын бер искәрмә ясарга кирәктер: дастаннар, озын—озын такмак, җырлар күбесенчә күчмә кабиләләр арасында туа һәм тарала. Алар бер җирдән икенче ерак җирләргә күчкән чакта, яки көтүләре белән сахра— далаларда каңгырап йөргәндә көнне кыскартып матур итеп моңланганнар, җыр-шигырь көйләгәннәр. Ә утрак тормышлы авыл кешеләре алай түгел, бетмәс- төкәнмәс йорт һәм кыр эшләре аларның вакытларын чикләгән, алар даладагы кебек үзләренең иҗат-

ларын ераkларга җибәрә алмаганнар. Шуның белән дастаннарның татарлар арасында аз булып яралуы, нугай, башкорт дастаннары һәм бәетләренең күп таралуы аңлатыладыр. Көнчыгыш халыклары авыз иҗаты әсәрләренең татарлар арасында таралуы һәм татарча вариантларының килеп чыгуы да шуның белән бәйле булса кирәк.

Алар арасында иң күренеклесе һәм Казан ханлыгына якыны - Идегәй дастаны. Ул XV- XVI гасырларда нугай халкында туып һәм тулыланып, Урта Идел буе татарларына да килеп кергән, үзенең берникадәр үзенчәлеген алып, татарча варианты булдырылган. Гомумән алганда, аның төп сюжет линиясе шул килеш калган. Сүз Алтын Урда идарәчеләре Туктамыш, Идегәй, Кадырбирде һәм Сәмәрканд әмире атаклы Аксак Тимер арасындагы мөнәсәбәтләр турында бара. Тарихи вакыйгалар киң планда эпик алымнар белән бирелгән. Татарча вариантта шулар ук кабатлана, аңа бары тик Болгар шәһәрләренең Туктамыш һәм Тимерләнг тарафыннан җимеррелүләре һәм Болгар җирләренең урыслар тарафыннан талануы турындагы өстәмәләр кертелгән. Дастанда мондый юллар бар:

Килә җитеп Идегәй
Болгарны танып танымый,
Хәйран калып туктады;
Алтынлап сүрә яздырган,
Ал бизәкле Айкапу
Айкапуны тапмады.
Айкапуның тупсасы,
Киң манара- ак яңак,
Ак яңакны тапмады.

Икенче бер урында ак сакаллы Бодайби бабай Идегәйгә сөйли:

Болгарым бүген бозылды...
Челдәй чәчем агарып,
Бодайби булып ни кылыйм?
Син дә булып ир булдың;
Сыенганым син идең,
Бу җиһанның фетнәсе
Аксак Тимер дошманны
Сарайга алып китердең,
Йөз баһадир иреннән
Йорт- җиреңне бастырдың.

Казанны да керткән Болгар җиренең җәфа - михнәт күрүләрен та-

тар халык дастаннары, күп санлы риваять— легендалары вә бәетләре тәфсилләп сөйли, дип яза фольклор белгече Ф.И. Урманчеев һәм бер өзек китерә:

Тимердән вә ташлардан салган биналар вәйран,
Ни сәбәптән улды вәйран, гафилләр улыр хәйран.
Иске ташлар, тирән базлар ятыр анда бу заман,
Әгәр кайтып күрер булса, танымас иде аны хан.
Җиһанны тетрәтмеш иде синең олуг шәүкәтең,
Кайда милкең, кайда гыйльмең, кайда бөек дәүләтең.

Татар халык иҗатында шул рәвешле чагылган вакыйгалар тарихи чынбарлыкта ничек булган? Бу соруга җавап бирү кирәктер дип уйлыйм. Болгар җирен Туктамыш хан 1382 нче елда буйсындыра, ә 1391 нче елда Болгар чиге буендагы Кондызча елгасы янында ул Аксак Тимер гаскәрләре тарафыннан зур җиңелүгә дучар була.

Бу вакыттагы сугышларны күз алдына китерә белергә кирәк Сугышчылар аерым гаскәри берәмлекләрне генә тәшкил итмичә, тулаем армия-халыкны туплаганнар. Мәсьәлән, Аксак Тимер чирүенең бер флангасы белән икенчесенең арасы йөз чакрымга сузылган. Сугышка керүчеләр артыннан бик күп олаулар, арбалар, ат һәм күп төрле терлек көтүләре барган. Ханнарның үзләре булмаса, армиянең башка төркемнәре күп урыннарга таралып эш итүләре мөмкин булган. Шунлыктан Аксак Тимер Болгарны үзе җимергәнме, түгелме, дигән сорауга «Үзе булмаса, башкалар булган», дип җавап бирергә туры килә. Чөнки халык телендә бу турыда, ягъни Аксак Тимерне каһәрләп, шул кадәр күп бәетләр, риваятьләр һ.б. тумас һәм калмас иде.

Алтын Урда күчмәннәреннән килгән бәлалар өстенә көнбатыш урыс кенәзлекләреннән булган талау походларыннан да безнең болгар җире иза чигә. Урыс елъязмалары (XV гасыр ахыры елъязма береклеге) болай дип яза: 1395 елда Мәскәү кенәзе бик күп гаскәр җыеп, үзенең туганы Юрий Дмитриевичны Бөек Болгар, Җүкәтау, Казан һәм башка шәһәрләргә җибәрде. Ул аларны яулап алды һәм бик күп мал алып кайтты. Мондый талау һөҗүмнәренең 1399 елда тагын да көчлерәк булуы турындагы мәгълүматларның байтагы урыс елъязмаларында теркәлгән. Ләкин шундый хәлдә дә Казан дәүләте үзенең көчен һәм мөстәкыйллеген югалтмаган. Шул ук елъязмада һәм башкаларында да Казан патшасы Ентякнең (Мазурин елъязмасында «Казанский царь Октяк» диелгән) 1395 елда Суздаль кенәзлегенә ярдәм йөзеннән Түбән Новгородка каршы поход ясавы әйтелгән.

Укучылар! XIII гасырдан башланган афәтләрне, XIV гасырның туксанынчы елларындагы вакыйгаларны күз алдына китерик әле. 1391 елда Туктамыш хан белән Аксак Тимер сугышы, 1395 елда яңадан алар арасындагы сугыш, боларның икеседә Болгар- Казан җиренә кагылмаган дип әйтеп булмый. 1396 елда урыс походы, 1399 елда тагын шуларның талау һөҗүме. Кешеләр башына никадәр бәла-каза! Боларны халык үзенең авыз иҗатында тасвирламый калдыра алмаган, билгеле.

Ахыргы искәрмә: Сугышлар, талау һөҗүмнәре күбрәк Кама аръягында, болгарның төп җирендә булганнар кебек. Каманың уң ягына, Казан дәүләтенә алар ул вакытта азрак булганга охшый.

Вакыйгалар булган, алар артыннан риваятьләр туган, аларны рифмага салып бәетләр әйтелгән. Хәтерем ялгышмаса, мәрхум Хәмит ага Ярми үзенең докторлык диссертациясендә бәетләрнең әнә шул тәртиптә килеп чыгулары һәм бәетләрнең тарихтагы зур вакыйгаларга, тарихи процессның борылыш ясаган моментларында барлыкка килүе турында язган иде. Шул фикерне дәлилли торган байтак бәетләр бар. Безгә аларның Казан ханлыгына караганнары әһәмиятле. Менә «Казан бәете»ннән берничә өзек:

Газыйлары күп иде, меллалары чук иде,
Галимнәре күп иде, заманы Ядегәр ирдея.
Бу җиһан нурлы иде, җәбер- җәфа юк иде,
Мөрит-мөршид күп иде, заманы хуп ирдея.
Галимнәре дуст иде, мөршидләре эштә иде,
Барча дошман түбән иде, заманы Ядегәр ирдея.
Ике йөз алтмыш ике ел Казан мөселман кулында,
Ахыры бары соңында урыс халкы алдыя.

Әлбәттә, риваятьләрдәге кебек үк, бәетләрдә дә ялгыш сүзләр, дөрес булмаган еллар һәм башка кимчелекләр бар. Мәсьәлән, шул ук Казан бәетендә Аксак Тимернең Болгар җиренә һиҗри җиде йөз (1300) елда һөҗүм итеп килүе, Казан шәһәрен Габдулла хан балалары Алтынбәк һәм Галимбәк салулары шундыйлардан. Аксак Тимергә карата халык нәрсә әйткән һәм аны ничек бәяләгән?

Мисаллар китерик.

Чыкты һиҗрәтдин җиде йөз илледә
Төште галямгә хараблык, зилзилә.
Үзе аксак, гакылы ахмак, фетнәдә
Золымны күрсәтте һәр җирдә.
Ни җавап бирер Хода каршында ул,

Сорса Алла каты вә җәза илә?
Йа, Илаһи, әйлә ул бәндәңне сән
Ахирәттә залим вә җаһил илән.

Шулай итеп татар халкы әмир Аксак Тимергә ләгънәт укыган, Болгарны җимергән дип үзенең каһәрен белдергән. Ә бу бит бер генә мисал. Халыкның мондый карашы башка язмаларда да, риваять, дастаннарда да чагыла.

Сөембикә турында берничә бик җылы бәет чыгарылган. Аларны аның үзеннән соңрак та иҗат иткәннәр. Тарихи вакыйгаларны эченә алган Сөембикә бәете моңлы да, кызганычлы да. Аның озыны да, кыскарагы да бар. Берничә өзек китерик.

Шәһәр тышында сугыш, эчендә тулган афәт,
Шул тынычсыз вакытта Сафагәрәем вафат.
Карыштылар морзалар, Мәскәү сүзен алмыйлар,
Каршылыкны Мәскәүләр миннән диеп аңлыйлар.
Казан Мәскәү арасында тагын бер сугыш булды,
Җиңелгәчтән казанлылар солыхка киңәш кылды.
Мәскәү соңгы солыхны башкаларга яд кыйлган,
Мине Мәскәүгә озатуны солыхка бер шарт кыйлган.
Казандагы түрәләр солыхка кул куйганнар,
Мине Мәскәүгә озатып, тыныч тормак булганнар.

Монда тарихи чынбарлыкка туры килә торган урысларның солых шарты турында әйтеп узарга кирәк. 1550 елда Иван Грозный Казан астында җиңелеп киткәч, Мәскәү Казанга ультиматум төсендә солых дәгъва итә. Кырымлыларны гаиләләре, бала- чагалары белән, шулар белән бер рәттән Сөембикәне дә баласы белән, Мәскәү кенәзлегенә әсир итеп бирергә. Ә аларның ир - яугирләре аңа кадәр үк инде әсир төшеп, Мәскәүдә җәзалап үтерелгән була. Казан идарәчеләре солых белән килешеп, бәлки дәүләтне саклап калырга мөмкин булыр, дип уйлаганнар булырга тиеш. Шуның белән бергә бу бәеттә Сөембикәнең аһ- зарлары, моңнары, аның Рәсәй төрмәсенә китүенә кайгыруы, елавы киң рәвештә сүрәтләнгән. Сөембикә образы, гомумән, татар халык авыз иҗатында да, матур әдәбиятта да хәзерге көнгә кадәр зур урын алып тора. Ул XVIII - XIX гасыр урыс әдәбиятында һәм сәнгатендә дә байтак тасвирланган, хәтта С.Н. Глинканың трагедиясе буенча балет та язылган һәм ул Петербургта куелган да.

Халык авыз иҗатының башка жанрлары кебек, бәетләр кешеләрнең уй - кичерешләрен чагылдырып кына калмыйча, аларның әхла-

гын тәрбияләүдә, эстетик зәвык бирүдә зур урын тоткан һәм тота.

Татар халык авыз иҗатының телдән телгә, буыннан буынга сөйләнеп, күчеп таралган зур жанрын әкиятләр тәшкил итә. Алар бик күп гасырлар аша үтеп, һәрбер тарихи чорда үзгәртелеп бу көннәргә кадәр килеп җиткәннәр. Әкиятләрнең кайсысы кайчан килеп чыгып, халык арасында сөйләнә башлавын тәгаен билгеләп булмый. Чөнки аларны кәгазьгә язып алу эше, теркәү бары тик моннан йөз-йөз илле еллап элек кенә башланган. Ә алар язма тарихтан бик ерак заманнарда ук барлыкка килеп, гасырлар буена халыкның зәвыгына, күңелен тәрбияләүгә хезмәт иткәннәр. Дию, пәриләр турындагы гаҗәеп хәлләрне бәян иткән фантастик әкиятләр бик борынгылар дип саналса, патшалар, байлар белән ялчы батраклар, солдатлар турындагы әкиятләр соңрак килеп чыгуы, әлбәттә, шиксез. Аларның кайберләре фантастик әкиятләр яки вакыйгалар белән бәйләнештә бирелсәләр дә, социаль каршылык темасын ачып күрсәтәләр. Мәсьәлән, «Патша белән солдат» әкиятендә нинди генә мифик күренешләр сөйләнсә дә, барыбер солдат җиңүче булып кала. Шулай ук «Шомбай» әкиятендә ялчының байны отуы һәм башка шуның кебек сөйләмнәрдә гади кешеләрнең өстенлеге, тапкырлыгы макталып, алар халык рухына туры китерелгәннәр. Хайваннар, кошлар белән бәйле әкиятләр, тормыш —көнкүреш турында сөйләгәннәре дә бик гыйбрәтле. Аларда кешеләрдәге яхшы сыйфатлар мактала, ә аларның тискәре яклары— комсызлык, әләкләү, яла ягу кебек начар сыйфатлары бик каты тәнкыйтьләнеп, эшләгән эшләре, гамәлләре өчен төрлечә җәзага дучар ителә.

Хәзер инде әкиятләр тумый диярлек. Аларны сөйләүчеләр дә кимеп, бетеп бара,бугай. Без аларны «Әкиятләр» китабыннан гына укып беләбез һәм фикер йөртәбез.

Гомумән, халык авыз иҗаты әсәрләре, шулар рәтеннән әкиятләр дә, кешеләрнең әхлагын тәрбияләүдә зур урын тоттылар һәм хәзердә әле шул изге бурычны үтиләр.

# 4. Матур әдәбият әсәрләре

Казан ханлыгының мәдәният, мәгариф һәм әдәбият өлкәсендәге хәзинәләрен барлый башласаң, гаҗәп бер дөньяга кергән кебек буласың. Ләкин аны өйрәнеп чыккач әлләни гаҗәп булып тоелмый башлый. Чөнки төп хикмәт аның бик бай булуында. Халкыбызның мәдәни һәм әдәби мирасы хәзер инде безгә бик кечкенә кебек күренә, чөнки аның күп өлеше безгә кадәр килеп җитмәгән, туздырылган, яндырылган, җиргә күмелгән һәм тагын әллә нинди казаларга юлыккан. Тарихта төрле хәлләр булганы билгеле. А.А.Горбовский үзенең «Загадки древнейшей истории» дигән китабында (М.,1971 - С.64) шундый бер мисал китерә: Бервакыт Иван Грозныйга хәбәр бирәләр, шәһәргә бер олау китап төяп сәүдәгәр килгән, ләкин китапларын берәү дә укый алмый. Патша: китерегез, бергәләп укып карыйк, ди. Һичкем укый алмагач, олавы белән китапларны яндырыгыз, сәүдәгәр безнең кеше булса, акча бирегез, ди. Шулай итеп, укый алмаганлыктан, китаплар юкка чыга.

Казан ханлыгы XVI гасыр уртасынача Ислам мәдәниятен, Көнчыгыш цивилизациясен үзенә туплап килгән бер дәүләт иде. Шушы бөек цивилизацияне юк итү XVI гасыр уртасыннан башланып, ничә йөз еллар дәвам итте һәм аның әһәмиятен, бәһасын югалту өчен әле хәзер дә көрәш бара.

Мәдәниятебезнең, әдәбиятыбызның ул вакытлардан калган өлешенә кыскача булса да күз салыйк. Менә Казан университетының иске кулъязмалар һәм борынгы китаплар бүлеге, әнә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать Институты архивындагы кулъязмалар һәм борынгы китаплар фонды. Нинди генә нәрсәләр, әсәрләр, язмалар, матур әдәбият истәлекләре юк анда. Никадәр байлык! Бу байлык кайдандыр калган мал түгел, ә үзебезнең фидакарь көчләребез — милләтебез уллары һәм кызлары тарафыннан түкми- чәчми дөньяның төрле әтрафыннан җыйган халкыбыз мирасы. Боларга тагын Татарстан милли архивында һәм милли музеенда тупланган хәзинәне дә өстәргә кирәк. Болар Казан ханлыгы чорыннан сакланып калган мәдәният һәм әдәбиятның кечкенә бер өлеше генә. Вәйран булганын һәм исән калганын бергә кушып санасаң, минем күз алдыма ифрат зур һәм бөек цивилизация мәркәзе килеп баса.

Әдәбиятыбыз мирасының кайбер мисалларына һәм мәсьәләләренә тукталыйк. Менә татар шәкертләренең XVIII гасырга кадәр дәвам иткән, ләкин бик ерактан башланган «Илаһи бәет» дип аталган җыруы (бәлки бәете, шигыре дисәң дә ярыйдыр) мәсьәләсе. Мин бу әсәргә

беренче тапкыр Борынгы актлар дәүләт архивында Пугачев баш күтәрүендә катнашкан татар крестьяннары хәрәкәтен тикшергән вакытта юлыктым. Әлеге архивның (Мәскәү, РГАДА) VI фонды һәм разрядының 416 номерлы эшенең икенче бүлегендә тупланган язмалар арасында «Илаһи бәет» дип исемләнгән шигъри юлларны күргәч, бу нинди дини язулар икән инде, аллага догалар микән, дип уйлап өлгермәдем, күземә

«Сусадым, су тапмадым, көйдем тәмам,
Ләпләрендән тартып үптем- кандым тәмам, ярәй.»

дигән сүзләргә төште дә, туктап калдым.

Укып чыккач, аларның дини язулар да, догалар да түгел, ә «Искиткеч шәп бәетләр» икәнлеген аңладым. 1964 елда 416 нчы эш тулы килеш микрофильм рәвешендә Казанга кайтарылды, чөнки ул тулысы белән татарча безнең бабаларыбыз тарафыннан язылган төрле эчтәлекле кәгазьләрдән гыйбарәт иде. Ләкин ул вакытта минем эш башка иде, татарларның Пугачев восстаниесендә катнашулары турында кандидатлык диссертациясен язып яклыйсым бар иде. Мин әдәбиятчы да түгел идем.

«Илаһи бәет»ләрнең килеп чыгу һәм таралу тарихын тикшеренүне, аларның әдәбиятыбызда тоткан урынын, әһәмиятен билгеләүне үз өстенә әле ул вакытта яшь, һиммәтле, хәзер инде атаклы галим Миркасыйм Габделәхәт улы Госманов алды. Һәм өзлексез, еллар буе эзләнеп өйрәнде, нәтиҗәдә гүзәл бер китап бастырып, югарыда әйтелгән мәсьәләләрне хәл итте. (Миркасыйм Госманов.Каурый каләм эзеннән. Казан, 1994). «Илаһи бәет»нең югарыда күрсәтелгән архив эшеннән алынган күчермәсе аның китабында тулысынча китерелгән. Шуннан берничә өзекне җиңелләштереп укыйк әле:

Һавадан коңгылдашкан каз имәсме?
Егетне шаштырган кыз имәсме, ярәй?
Кызның малы кырык тәвә - аз имәсме?
Кыш көне кочып ятсаң, яз имәсме, ярәй?

Әссәламәгаләйкүм, өлкән кызлар,
Оят булыр, бөркәнчегең бөркән, кызкай, ярәй;
Бөркәнчегең күтәреп кем күрәдер —
Сәнең өчен нәфис җан шул уладыр, ярәй.

Бу җыр—бәетләр XVIII гасыр шәкертләре иҗаты. Ләкин аларның башлангычы Казан ханлыгы чорыннан, хәтта аңа кадәрге дәверләрдән үк килү ихтималы бар икән. Галимнең татар халкы яшәгән төбәкләрдә,

алай гына да түгел, төрки халыклар утырган барлык җирләрдә диярлек эзләп тапкан нөсхәләренә анализ ясавы дәлилле рәвештә әнә шул фикерне раслый. XVIII гасыр шигырь—бәетләре үзгәртелгән, яки үзгәреш кичерә торган вакытта иҗат ителгәннәр икән. Ә төп чыгышлары Казан ханлыгы чорындагы туй йолаларына, туйда җырлана торган такмакларга дип әйтимме, барып тоташа икән. Менә алардан кайбер мисаллар:

Хак мөбарәк әйләсен туеңызны, яр-яр;
Алтын-көмеш коршасын буеңызны, яр-яр.

Ун бишкә йитдисә яшькә кыз угъланың, яр-яр;
Җөмлә галәм бәһасе ялгыз кашы, яр-яр.

Җөмлә сачәкләр суладыр көз булса, яр-яр;
Кыз угълан йөзе сулар дәвере узса, яр-яр.

Кызы әйтүр анага, бармаем, анам, яр-яр;
Асрадың, хәләл ит, китәм, атам, яр-яр;

Өзәңгегә аякым куйдым, атам, яр-яр;
Ак сөтеңне хәләл кыл, бардым, анам, яр-яр.

Миркасыйм Госманов «Яр-яр» әйтү гадәтенең борынгы татар чынбарлыгында киң таралган йола икәнлеге тулысынча раслана, ди. Һәм татарларда гына түгел, ә борынгы төрки халыкларда да булганлыгын Галишир Нәвои, Заһиретдин Бабир иҗатлары аша исбат итә. Аңа өстәп «Яр» төшенчәсенең XVI йөз Казан шагыйре Мөхәммәдъярның «Нуры содур» поэмасында да урын алуын әйтеп узабыз (Мөхәммәдъяр. Нуры содур.- Казан, 1997- 142,146, 164 битләр)

Нәфсең атыңны сыйлама син, и яр,
Ул екмасын сине менәрдә, зинһар.

Рәхмәтеңне мин моңлыга яр-дуст ит,
Шәфкать күреп, очрашырга насыйб ит.

Гүзәл холыклы яманны яр итмәс,
Кирәкмәстән шәп дип, үзен хур итмәс.

Үгетне тот син үзең дә яр- дускай,
Яхшы күреп, ярдәм дә итәр Ходай.

Мөхәммәдъяр иҗатына махсус тукталырбыз әле, ә хәзер «Яр-яр» ның «ярәй» гә үзгәрүен XVIII гасырдагы сәяси—иҗтимагый, икътисади-мәдәни сәбәпләргә калдырып, аның ул вакыт вәзгыятендәге

әһәмиятенә күз салыйк. Билгеле инде, туй җыры яшьләргә бәхет, уңышлар һәм мул тормыш теләүләр белән барган. Ләкин алар белән генә чикләнү дә бик үк тулы булмас иде. Гомумән алганда «Яр-яр» җыруы - ул гаилә тәрбиясе. Аның тәрбияви әһәмиятен шунда китерелгән парчалардан да күрергә була. Мәсәлән:

Туйны төзек кылдылар сезләр өчен, яр-яр;
Нитәк ки баг төзделәр гөлзар өчен, яр- яр.

Яки: Егет зиннәтле имешдер адәм ара, яр-яр;
Кыз угълан хуш бизәнер галәм ара,яр-яр.

Һәм соңгысы: Хәмәд - сәна итәлем — Алла яды, яр-яр,
Бирде ходай бу кичә сән зибаны, яр-яр.
Һәр сүземдә хуш булсаң, егетләрчә яр-яр,
Ошбу сүзем нәсихәт белгәннәргә, яр-яр.
Ошбу җаным җиһанда корбан улсын, яр-яр,
Көн-төн дога кылыңыз үлгәннәргә, яр-яр.

Шуның белән бергә теләкләр һәм үгет-нәсихәтләр Аллаһы Тәгалә һәм аның пәйгамбәре Мөхәммәт галәйһисәламның хәер -фатихасын алуга өмет итү, аларга дога сүзләре әйтүдән башлана, шул рухта дәвам ителә. Кыз да, егет тә бик макталалар, аларны яратып җиңелчә шаярталар. Хәзер инде туй мәҗлесләрендә башкача җырлыйлар, башкачарак шаярталар. Тик борынгы йолаларыбыз да матур һәм гади булганнар икән, аларны хөрмәт итү - бабаларыбызны олылау ул.

Казан ханлыгы чорыннан калган башка лирик әсәрләр, шигъри парчалар бар. Аларның барысына тукталмыйча, төрле формаларда сакланганнарын карап узыйк. Мәсәлән, таш язуында калганы:

Ходаның рәхмәте улсын анларга,
Анлар лайык иде дога кылырга.
Йикерме алтыда улды фәнасы,-
Йыкылды ташының бер хуп бинасы

Бу язулы таш 1528 елда куелган булган. Ә түбәндәгесе 1522 елда куелган:

Үлем куанычысы йитте,
Безем куанычымыз китте.
Мәгәр шонкар булып очты...
Өметләрне өзеп китдәчи...
Киткән йикет, җаным куанмай,

Тилмереп көткән йикет җаным алгай.

Беренчесендә газиз балаларын югалткан ата- ана зары булса, икенчесендә егетен соңгы юлга озаткан кыз-кәләшнең кайгы, моң— зары. Шул ук вакытта алар матур әдәбият стиленә дә туры килә һәм поэзия үрнәкләре булып саналырга мөмкин.

Бу фикернең дөреслеген Г.Рәхим, Г. Гәзиз (Татар әдәбияты тарихы.- Казан, 1925.- 1 кис.) һәм башка әдәбиятны тикшерүчеләр раслый. Ә Шиһаб Мәрҗани болай дип әйтә: «Башларында шигырь кителгән бик матур язылган ташлар бар, һәм ул вакытларда ук биредә һөнәрле, яхшы белемле кешеләр яшәгәннәр икән, дигән фикергә киләсең». Казан кешеләренең көнкүреш җиһазларын матур бизәкләр белән зиннәтләндерүе, аларга шигъри юллар язып куюлары да билгеле.

Йөзиңе күрдем имди күзләримән,
Йакларика тел ки нагяһ булмакы мән.
Аның йөзине күрки, нә мәйел, и...

«Татар әдәбияты тарихы» ның беренче томы «XV-XVI йөзләрдә татар әдәбияты» кисәгендә (Казан, 1984-288 б.) «Ул вакытта матур әдәбиятның төп жанры булган хикәят урта гасыр болгар- татар җирлегендә башлыча гарәп һәм фарсы телләрендәге әсәрләрнең тәрҗемәсеннән яисә аларга таянып язылган әсәрләрдән гыйбарәт була» дип әйтелгән. Моңа искәрмәләр кирәк дип уйлыйм.

Әлбәттә инде, шигырьләр, җырлар һәм бәетләр кәгазьгә дә язылганнар, күчерелгәннәр. Аларның кайберләренең исемнәре дә билгеле. Ләкин ул турыда сөйләгәнче берничә фикер бар.

Казан чоры матур әдәбиятында, минемчә, төп жанрны хикәят түгел, ә шигърият тәшкил иткән. Шигъриятнең өстенлек итүе соңрак та, XVII - XVIII йөзләрдә дә дәвам иткән. Мәүла Колый, Кандалый иҗатларына күз салсак та шуны күрәбез. Ничек кенә уйласаң да, нәрсә генә әйтсәң дә, шигърият жанрының төрле формалары (җыр, бәет, шигъри парчалар, такмаклар) чәчмә әсәрләргә, хикәятләргә караганда күбрәк сакланып калган. Минем уемча Көнчыгыш илләрендә һәм халыкларында бу хәл гомуми төсне дә ала кебек, ягъни аларда лирика көчле үскән. Ләкин бу чәчмә әсәрләр бөтенләй булмаган дигән сүз түгел, алар да булган. Бигрәк тә дини хикәятләр, пәйгамбәрләр тормышыннан алынган һәм «коръәни» кыйссалар күп булган дип уйларга кирәк. Мораль- этик эчтәлекле, нәсихәт бирүче әсәрләрнең булуы да билгеле.

Безнең халык тирә- күрше һәм төрки халыклар арасында беренчеләрдән булып хикәят язудан романнар язуга XIX гасыр ахырында

гына көчте. Рәсәйдә дә романнар язу шул ук XIX йөздә башланды. Хикәят кешенең бер халәтен, тормышының бер вакыйгасын сүрәтли, ә роман инде кешеләр тормышының катлаулы вакыйгаларын, мизгелләр белән чикләнмичә озын гомерне тасвирлый. Мин боларны чәчмә әсәрләрнең соңрак үсеп чыгуына ишарә итү өчен теркәп куйдым.

Ул вакыттагы әдәбиятның хронологик һәм географик киңлеге дә бик зур булган. Кешеләр үзләреннән элек булган иҗат җимешләреннән киң файдаланганнар, аларны кадерләп саклаганнар, кабатлый-кабатлый үстергәннәр һәм баетканнар. Борынгы «Кисекбаш», «Бәдавам», «Нәсихәтес - салихин» кебек әсәрләрнең ул чорларда кулдан төшми укылуы һәм башка хикәяләрнең әллә кайчаннан бирле кулланышта йөрүе шул турыда сөйли булса кирәк.

Казан кешеләре болгар заманы әдәбияты белән дә таныш булганнардыр, Кол Галинең «Кыйсса и Йосыф»ын да укыганнардыр.

Ләкин мин бу мәсьәлә буенча мәгълумат тапмадым, ул Мөхәммәдъяр поэмаларында да сизелми. Географик киңлек турында сөйләгәндә әдәбият тарихын тикшерүчеләр Казан дәүләте вакытындагы мәдәнияткә һәм әдәбиятка бик күп Көнчыгыш илләренең һәм халыкларының иҗади җәүһәрләре үтеп керүе турында язалар. Мөхәммәдъяр иҗатының белгече Шакир ага Абилов шагыйрьнең образлары Йосыф Хас-Хаҗибның «Котадгу белек» (XI г.), Низаминың «Хөсрәү вә Ширин» (XII г.), Котбның «Хөсрәү вә Ширин хикәяте» (XIV г.), Нәваиның «Фәрхад вә Ширин» (XV г.) әсәрләре белән охшаш һәм аваздаш дип күрсәтә. Икенче бер җирдә ул «Әзәрбайҗан, үзбәк, госманлы, төрекмән әдип һәм шагыйрьләреннән Әхмәдинең «Искәндәрнамә»се (XIV г.), Мир Хәйдәрнең «Мәхзанел - әсрар» ы (1409 -1414), Дурбәкнең Бәлехтә язылган «Йосыф вә Зөләйха»сы (1409), Лотфиның «Гөл вә Нәүруз»ы (1411), Мөхәммәд Чәләбинең «Мөхәммәдия»се (1499), Язычы углының (Әхмәт Биҗанның) «Әнварел- гашикыйн»ы (1450-1460), Вафаиның «Рәүнәкыль - ислам»ы (1464-1465), Бәйдаба «Кәлилә вә Димнә»сенең һәм Гаттар «Пәнднамә»сенең төрки телгә тәрҗемәләре (XV-XVI гг.), Физули һәм Нәваи кебек шагыйрьләрнең әсәрләре татарның үз язучыларыныкы кебек яратып укылган», дип яза. (Татар әдәбияты тарихы. 1 том. Казан, 1984- 288-289 б.)

Казан дәүләте шагыйрьләренең кордашы казакъ акыны Асан Кайгы казакъ, татар халыклары арасында яшәп үзенең иҗатын аларга багышлаган икән. Аның моңлы, ачык һәм төгәл фикерле шигырьләре әле хәзер дә тирән ихтирам уята:

Таза, менсез асыл таш
Су төбендә җатады;
Таза, менсез асыл сүз
Уй төбендә җатады.
Су төбендә җаткан таш,
Җил толкытса, чыгады;
Уй төбендә җаткан сүз,
Шер толкытса, чыгады.

Менә аның тагын бер шигыре:

Ул көндә карендәштән хәйер китәр,
Ханнан - көн, карагайдан чапкын китәр.
Улың-кызың урыска бу тәм булып,
Хәйран ил- Идел йортым шунда нитәр?

Мондан соң байтак- байтак заман булар,
Заман азып, әхлак тузып, җиһан тулар,
Карагайның башына чуртан чыгып,
Бәлаләрнең болгануы тәмам булар.

Болардан шагыйрь үз дәверен бик яхшы тоеп яшәгән икән дигән фикер кала. Тарихи күрә белүчелек тә сизелә монда. «Татар поэзиясе антологиясе»ндә аңа карата шундый белешмә бирелгән: «Ул, Олы Мөхәммәд хан урдасында булып, 1437 елда аның белән бергә Болгар—йортның үзәге Казанга күчеп килгән». Кайдан алынган мондый магълүмат — билгесез. Олы Мөхәммәднең Казанга үзенең килүе дә бик бәхәсле, югыйсә.

Әдәбиятыбыз тарихында күптәннән билгеле булган, чыгышы буенча госманлы шагыйрь Өмми Камал да татар поэзиясенә күп өлеш керткән. Аның турында олы әдәбиятчыбыз Мөхәммәд Гали болай дип язды: «Без Өмми Камалны татарның борынгы чор шагыйрьләре сафына кертергә, хәтта аны саннары дистәдән узган ул чор шагыйрьләре тезмәсенең беренче төймәсе итеп куярга хакыбыз бардыр дип беләм», һәм ул «татарның борынгы һәм соңрак чор поэзиясендә үзенең эзен дә калдырганлыгы ачык». (Гали М. Өмми Камал китабы // «Совет әдәбияты», 1941, № 5-53 б.) Югарыда «Казан дәүләте шагыйрьләре» дип мин шул вакытта яшәгән һәм иҗат иткән Гарифбәк, Кол Шәриф, Мөхәммәдшәриф, Касыйм шәех кебек шәхесләрне һәм 1507 елда Казанда тәркичә тәфсир, 1552 елда «хәдисләр җыентыгы» һәм 1591 елда «Бөстанел — кодес вә Гөлстанел—өнес» дигән хикә-

яләр җыентыгын төзүчеләрне күзаллап әйттем. Казан галимнәре, шагыйрь һәм язучылары башка илләрдә, башка халыклар арасында да иҗат иткәннәр, аларга да хөзмәт күрсәткәннәр. Мәсәлән, Мөхәммәд Әмин әл- Болгари 1146 елда язылган борынгы «Шифа» китабын 1468 елда Болгар җирендә (бәлки Казандадыр), аннары 1473 елда Гыйракта күчереп яза, шәрехләр төзи.

«Татар поэзиясе антологиясе» китабында (1 том, Казан, 1992) Казан ханлыгы чорына караган унлап шагыйрьнең иҗатыннан мисалләр китерелгән. Югарыда әйтеп узылган шәхесләрдән башка анда тагын Мөхәммәд Әмин, Мәҗлеси, Максуди, Кол Шәриф шигырьләре һәм Казтуган, Дусмәмбәт, Чалгиз җыраулары урын алган.

Мөхәммәд Әмин Казан ханы булып торган вакытында (1487-1496, 1502-1518) үз тирәсенә укымышлы кешеләрне, шагыйрьләрне, музыкантларны һәм рәссамчыларны туплый, үзе дә шигырьләр яза. Атаклы Бабур хан аның турында матур әдәбият сөюче, нәфис сүз һәм матур зиннәтле әйберләр яратучы дип язып калдырган.

Мәҗлеси дигән шагыйрь «Кыйссаи Сәйфелмөлек» дигән дастан язган. Үзе Хәрәзм төркиләреннән булса да, аның бу әсәре Урта Идел буенда бик киң таралып, бөтен татар халкының яратып укый торган китабына әйләнгән. Аның чәчмә формалары да барлыкка килгән. 1807 елда ук беренче мәртәбә татарча басылган матур әдәбият китабы була.

Максуди дигән шагыйрь Казан ханлыгы чорында яшәгән. Аның 1515 елда төзегән шигырьләр жыентыгы безгә кадәр килеп җиткән, 1848 елдан башлап Казанда берничә тапкыр басылып чыккан. Ул үз вакытында булган тормыш үзенчәлекләрен, халыкның рухи халәтен күрсәтүе белән аерылып тора.

Аңардан бер мисал:

Күр дөньяны: нә йавыз хәлләре бар,
Җөмләй алдар, меңләп хәйләсе бар.
Ул ки, тупас, халкы аптыраштa идәр,
Мөлкәтләре таланып, кан итәр.

Масуди иҗатында кайгы-хәсрәт авазлары, аллага сыену мотивлары көчле бирелгән.

Югарыда исемнәре аталган Казтуган, Дусмәмбәт һәм Чалгиз казакъ һәм нугай импровизатор- шагыйрьләренең әсәрләре татарлар арасында да таралган булган.

Инде Мөхәммәдъяр иҗаты турында. Аның хакында күп язылган булса да, безүзебезнең күзаллавызны китерергә булдык. Чөнки

Мөхәммәдъяр иҗаты - ул бөтен Казан ханлыгы чоры поэзиясенең иң югары ноктасы һәм аның үзенә күрә йомгагы. Татар халкы мәдәниятен үстерүдә аның тарихи әһәмияте бик зур. Аның иҗатын өйрәнү мәдәниятебез тарихын күзаллауга нык ярдәм итә.

Баштан ук әйтеп китәргә кирәк, Мөхәммәдъярның иҗаты Аллаһыга һәм аның пәйгамбәре Мөхәммәткә тирән ышану, аларга табыну белән, зур хөрмәт һәм ихтирам белән сугарылган. Алланы олылау һәм мактау, аңа догалар кылу бер яки берничә урында гына түгел, ә әсәрләренең башыннан ахырына кадәр сузыла. Бу турыда элегрәк, үткән гасырның 90 нчы елларына кадәр бик аз әйтелде, чөнки әле коммунистларның дингә каршы дошманлык идеологиясе хөкем сөрә иде.

«Төхфәи Мәрдан» поэмасы:

Илаһи, син юмарт, ризык бирүче,
Бер син, бар син, рәхим, гафу итүче.

юллары белән башланып китсә, «Нуры содур» поэмасы:

Барча серләрне беләсең, Илаһым,
Мин — языклы колың, күптер гөнаһым.

дип башлана. «Төхфәи мәрдан» әсәре:

Сөеклебез (Пәйгамбәребез), яклаучыбыз бул безгә,
И Ходаем, ул киңәш итсен безгә.

тәмамланса, «Нуры содур»:

Тәмам булды «Нуры содур» китабы,
Нидер фәкыйрь күчерүче гөнаһы.

дип бетә, ягъни «фәкыйрь» шагыйрь алла каршында үзен гөнаһлы саный.

Әлбәттә, поэмалар, гомумән Мөхәммәдъяр иҗаты аллага сыгыну, аның шөһрәтенә дан, мәдхия җырлау белән генә чикләнмәгән, ә бик күп дөньяви мәсьәләрне яктырткан. Алар безнең бүгенге көнкүрешебезгә хас булган хәлләрне дә, кешеләр арасында булган мөнәсәбәтләрне дә чагылдыра.

«Төхфәи мәрдан» поэмасында Аллага һәм аның пәйгамбәренә дога кылып бетергәч, ул үзенең кичерешләре, уй-хисләре белән уртаклаша:

Гакылың булса, җирдә калдыр сүзеңне,-
Укыганнар ахыр данлар үзеңне.

Тагын шул ук бүлектә:

Бу шәһәрнең гаҗәп тулы эче дә:
Шагыйрь булган барча олы- кече дә.

Казанда ул вакытта ук шагыйрьләрнең күп булу факты югарыда телгә алынды. Бу турыда поэманың шаһ Һарун бүлегендә тагын бер мәртәбә языла. Һарун әр Рәшид (786-809) гарәп Габбасилар династиясенең бишенче хәлифәсе. Аның турында Көнчыгыш риваятьләрендә күп мәртәбәләр гадел падишаһ, акыллы һәм намуслы хөкемдар дип сөйләнә. Мөхәммәдъяр әсәрендә вакыйгалар болай тасвирлана. Һарун әр Рәшиднең бер бик яхшы шагыйре Хушнавәдән көнләшеп, вәзирләр аның өстеннән шаһка керәләр һәм:

«Башы тишек, дивана ул, диделәр,
Йолкыш, әләкче, фетнәче, диделәр.
Һәр вакытта фетнәчел һәм сәрхуш ул,
Күккә ашкан мәлдә дә кол булыр ул».

Шулай әләкләп, Хушнавәне җавапка тарталар. Шаһ каршында әләкчеләр һәркайсы бер бер артлы шагыйрьгә гаеп ташлый, Хушнавә аларга аерым— аерым җавап бирә. Тойгысунга Хушнавә җавабы:

Акыллы ир: мин - олы, дип мактанмас,
Андый затта тәкәббер, кинә булмас.
«Синнән артык —мин», дип авыз ерасың,
Эчтән сасы, бозык эшләр корасың,
Синдәй этләр ерактан күп өрәләр,
Ишеккә килдисә,«чык!» дип сөрәләр.

Икенче гайбәтче шагыйрьне болай битәрли:

Яшь түгәсең —бер матурга күз салсаң,
Тиз бизәсең, шаһтан берәр сүз алсаң.
Табылмастыр миңа тиң бер хуш аваз,
Үзе миннән оялачак моңлы саз.

Моңа каршы Хушнавә:

Әйтте: «Синдә һичбер инсаф күренми,
Шапырынма—ни дә кулыңнан килми.
Үзеңне син галим, тугры саныйсың,
Сөюгә дә дәгъва белән яныйсың.
Ни файда бар дәгъвадан, мәгънә кирәк,
Алдан — мәгънә, тик соңын дәгъва кирәк.

Өченче кеше Чынбил матур сүзләре белән һәм гадел булырга тырышып, ике тарафны килештерергә омтыла. Аны шуның өчен Хушнавә дә мактый.

Дүртенчесе исә тагын шагыйрьгә ташлана һәм начар сүзләр әйтә. Аңа каршы шагыйрь:

«Аллаң —мәзһәбен белмәүче татар син

Бу дөньяда һәм эттән дә начар син»
Әшәкесең. Йөзең йәмсез—карарга,
Эчең—тышың тулы гайбәт сатарга.

Шаһ Һарун әр Рәшит үзенең хөкемен чыгара: өч гайбәтчене дә әләкче санап урыннарыннан алырга, Хушнавәгә ирек бирергә һәм Чынбил белән икесенә дә күп бүләкләр биреп, аларга беркемнең дә зыян итә алмасын шарт итә.

Мин югарыда шагыйрь иҗатының безнең көннәргә дә аваздаш булуын әйтеп узган идем. Әйтик, бүгенге бер кешенең менә мондый холкы. Ул үзенә кирәк кеше янына бара да, үзен кызгандыра башлый; мине кыерсыталар, яки кыерсыттылар, фәләнне эшләмәдәләр, мине тыңламадылар һ.б. сөйләп, миңа юл бирмиләр, миңа каршы хөсетлек кылалар дип дәгъвалар яудыра башлый. Акрынлап үзен мактауга күчә һәм башкалардан да шуны таләп итә. Мөрәҗәгать итүчедән үзен яклауны, ярдәм итүен сорый башлый. Бу сөйләүләрдә, әлбәттә инде, аерым шәхесләргә яла ягыла. Ул фәлән—фәсмәтән, нәкъ менә Мөхәммәдъяр әйткәнчә:

Җаен карар, һәрчак вакыт саклар ул,
Аңа нәүбәт җитсә, корт күк кадар ул.

Бу кеше шулай итеп яла ягулар, гайбәт сатулар һәм әләкләүләр юлы белән үз мәнфагатьләренә ирешергә тырышып йөри. Кайберәүләрне ышандыра да, үзенә теләктәшлек тә таба, хәтта кайбер түрәләрне дә үзенә тарафдар итә. Тагын бер сыйфаты — ул бер-бер уңышсызлыгына очраса, моны миңа каршы оештырганнар, бу фәлән кешенең эше булырга тиеш, дип саный һәм тикшереп, эзләнеп йөри башлый. Мондый тар күңеллелек, түбәнлек, кешелексезлек Казан ханлыгы чорында да булган икән, хәзер дә бар. Үз вакытындагы һәм безнең бүгенге көннең мондый шәхесләренә Мөхәммәдъяр киңәш итә:

Аңың булса, иргә итмә явызлык:
«Кое казып, үзе төшкән»,- ди халык.

Әмма кызганыч, матур әдәбият никадәр көч куймасын, кешеләр калебен үзгәртеп, чистартып бетерә алмый шул.

Мөхәммәдъяр әсәрләрен бастырып чыгаручы Шакир ага Абилов «Төхфәи мәрдан»га биргән 40 а искәрмәсендә болай дип яза: «Үзара бәхәс вакытында персонажларның берсе икенчесен «татар» сүзе белән сүгә. Моны кайберәүләр татар халкына бәйләргә, Мөхәммәдъяр татарны яратмаган дигән фикерне үткәрергә тырышалар. Бу мәсьәләгә тарихи килергә кирәк». Ә ничек тарихи килергә кирәклеге әйтелмәгән. Тарихи яктан караганда менә болай килеп чыга. Борынгы татарларның исеме күптәннән һәм бик ерак җирләргә таралган була. Ләкин алар XIII гасыр башында таркалып, җиңелеп, кырылып бетәләр, аларның исемнәре генә кала. Ә европалылар шул ук монголларны һәм аларга кушылган төрки кабиләләрне дә иске исем белән «татар» дип атый бирәләр. Шул ук исем урысларда да таралып кала. Монда шул гына бар: этноним (исем) белән җисемне (халыкны) бутамаска гына кирәк. Чынгыз хан татар дип аталган кабиләләрне юкка чыгарып, кырып бетергәч, аның империясендәге монгол һәм башка кабиләләр арасында татар сүзен күрә алмаучылык, нәфрәт көчле була һәм мондый мөнәсәбәт Батый хан белән килгән Алтын Урда монгол һәм төрки кабиләләрендә дә кала.

Мөхәммәдъяр әнә шул күзлектән чыгып әйтергә мөмкин. Европалыларның һәм урысларның монголларны да кертеп барлык Алтын Урда халкына татар исеме бирелгәнлектән чыгып әйтүе шикле, чөнки ул бу халыкка андый нәфрәт сакламаган.

Моннан соң автор бераз күңелен юатып ала, борчылуларын таратырга теләп ханга (падишаһга) киңәшләр бирә:

Бер яхшыны кылсаң,—унны алырсың,
Унны бирсәң — урнына йөз алырсың.

Алгарак китеп, ул хак тәгалә үзенең вәгъдә иткәннәрен үтәп, бәндәләренә йөзен күрсәтеп, аларны сөендерәчәге турында озак кына нәсихәт итә һәм дога укый.

Бүре һәм падишаһ кызы турындагы бүлектә әкияти бер вакыйга сүрәтләнә.

Александр Македонский заманындагы бер падишаһ төннәрен бер өйдә ике кешенең сөйләшүен ишетә. Имеш, йорт хуҗасының кызы бик гүзәл, тик ундүрт яшендә аны бүре ашарга тиеш дип тәңренең әмере булган. Патша кызны кызгана, атасына мал биреп үзенә алып кайта һәм аны яше җитә башлагач бер ел буена таш бинага яптырып

саклап калмакчы була. Ялгыз булмасын, дип, янына икенче бер гади кызны кертәләр. Ә ул Илаһыдан бүре булуны сорый һәм догасы кабул кылынып, бүре була һәм патша кызын ашый.

Шагыйрьнең әйтәсе килгән сүзе, югарыдан иңгән тәңре теләгенә каршы килмәскә, аны тыңлап сабыр булырга кирәк. Падишаһ әйткән, ди:

«Кодрәтле Аллам,—диде,—тудыручым,
Тәүбә иттем,кичер син, туйдыручым».

Автор бик нәфис итеп, югары иҗади киеренкелектә язмыш белән сөйләшә.

Зарлана да, алладан ризалык, ярдәм дә сорый һәм нәсихәт укый:

Ир дип аталганга батырлык кирәк,
Галим һәм гадигә юмартлык кирәк.
Китер бүген кешегә син файда тик,
Гаклың булса, ир күңеленә салма шик.

Шуннан соң «Заһид хикайәте» китерелә. Заһид коега төшкән маймылны, еланны, капланны (барсны) һәм Зәргәр дигән бер кешене тартып чыгара. Заһид хайваннарда бик хөрмәтле кунак була. Каплан Заһидка бүләккә дип, бер бәкнең кызын буып, кыйммәтле хәситәне ала һәм ул турыда Зәргәрне очраткач, аңа сөйли. Зәргәр шунда ук мал алам, дип бу хәбәрне бәккә җиткерә. Үзен улемнән коткарган кешене мал өчен сата. Заһидны асарга дип зинданга явып куялар, ләкин моны елан күреп кала. Елан хәлне белгәч, Заһидка дару үләне бирә, шуның белән бәк кызын терелтерсең, ди. Үлгән терелә, ә Заһидниләр булганын бәккә сөйләп бирә.

Ул илдә тәртип иде: ялганчыны
Үтерәләр иде —бөһтанчыны.
Астылар Зәргәрне чыгарып дарга,
Имин калды Заһид хаклыгы барга.
Яман иде Зәргәр, игә килмәүче,
Бәдбәхет бер, яхшылыкны белмәүче.

Мөхәммәдъяр хикәятен тәмамлагач, үзенең рухи халәте турында яза, кешеләрне хезмәткә өнди, тик ятма, уяулыктан ирешерсең бүләккә, ди. Бер азгын, зур гөнаһлы бәндә ике тапкыр яман эшләрдән тәүбә итеп тә яхшы юлга басмый торгач, каты авырый һәм анасыннан сорый: мин үлгәч аллаһыдан үтенә күр, мине гафу итсен. Анасы алладан бик үтенеп, догалар укып баласының гозерен үти. Аллаһы Тәгалә ана догасын кабул итеп баласын тергезә. Шагыйрь алгарак китеп, күндәм хезмәтче исе-

меннән, бөтен халыкка киңәшләр биреп мөраҗәгәт итә.

Теләә: явыз нәфседән котылырга,
Яхшы килсә берәүгә—шат булырга.
И намуслым, изге кыл һәр кешегә,
Ул һич кылмас мәкер синең ишегә.
Бозык якка күз салу һич кирәкмәс,
Булмас сүзгә колак тоту кирәкмәс.
Үзеңнән бер яшькә зурны хөрмәт ит,
Кечегә дә, олыга да шәфкать ит.

Бер карун, саран кеше була. Аның кызы бер теләнчегә икмәк бирә. Әтисе моны күреп, бик нык ачулана, кызның кулын кисә һәм өеннән куып чыгара. Атасы алладан җәза ала, корсагы шартлап ярылып үлеп китә. Кыз бик чибәр була, матур бер егет белән кавыша, кулы да төзәлә, игелек белән озын гомер итәләр. Мөхәммәдъярның бу гыйбрәтле хикәяте дә безнең тормышка аваздаш. Азмыни хәзер дә мал өчен комсызланып, кул кисү генә түгел, аталары балаларын, балалары ата—аналарын үтерүләре. Болар турында газета—журналлар әледән әле яза, телевизордан күрсәтеп торалар. Шул ук нигездә көнләшү аркасында бер—берләрен талыйлар, яман сүзләр чыгарып, даулашалар, сугышалар. (Көнләшү әсәрләрдә «кинә» сүзе белән бирелгән).

Ярлы кешеләр тормышыннан түбәндәгечә мисаллар китерелә:

Аларның бу көнкүреше тар иде,
Тормышта бер тәңкәләре бар иде.
Ярымына алып алар аш—икмәк,
Ярымына мамык алып һәм эрләп:
Аны хатыны җегерләп, җеп итеп,
Ире сата торган иде чыгарып.

Сабыр булып, түземлек белән хезмәт итеп, алар баеп китәләр. Ахырда бер хикәят сөйләнә. Булган ди бер карак, талаучылар бандасы.

Юл басып мал алу иде эшләре,
Кайда яман булса — иде эшләре.

Аларны бетерү өчен патшадан көч сорыйлар һәм банда тотыла. Вәзир шунда бик чибәр бер егетне үзенә бирүне сорый, мин аны тәрбия кылам,ди. Патша кирәкмәс эш эшлисең, ут белән мамык дус булмас, ди. Ләкин түбән әхлаклы кешене игә китереп булмый икән. Егет үз ишләрен тагын таба, вәзирне һәм аның ике улын үтереп, ма-

лын алып качып китә.

Һәркем итә икән үгет—сал колак,
Нәсихәт алмаганның эшенә бак.
Олыларның сүзе безгә—хикмәттер,
Һәркемгә дә нәсихәт—хуш, кыйммәттер.

Уйлап карыйк әле. Мөхәммәдъяр язган хәлләр безгә, безнең тормышка аваздашмы? Һәркемгә билгеле, бездә, Казанда гына да ничәмә банда, никадәр җинаятьчел төркемнәр булды һәм бар. Алар барысы да халкыбызга никадәр зыян-зарар китерде – санап бетергесез. Төрмәгә эләгеп утырып чыкканнарының берничәсе генә хак юлга баса, күбесе исә һаман үзенең элекке җинаятьчелек юлына әйләнеп кайта. Димәк Мөхәммәдъяр бүген дә хаклы, аның әйткәннәре бүген дә зарур.

«Төхфәи мәрдан» поэмасы Казанда Сафагәрәй хан дәверендә язылган. Әсәр, авторның үзе әйтүенчә, һиҗри белән 946 елның шәгъбан аеның унынчы көнендә башланып, айның ахырында тәмам булган. Ягъни, безнең календарь буенча 1539 елның 21 декабрендә башланып, 1540 ел гыйнварының 10 сында беткән була.

Мөхәммәдъяр моңнар шагыйре булган, ул гади халыкның авыр тормышын яхшы күреп белгән, аның рәтенә үзен дә кертеп, халыкның кайгы— хәсрәтен җырлаган. Әсәр һичшиксез Казан шәһәрендә язылган.

Поэманың тексты күзәтү өчен Ш.Ш.Абилов әзерләп чыгарган «Мөхәммәдъяр. «Нуры содур» китабындагы «Төхфәи мәрдан»ның тәрҗемәсеннән алынды.

Инде шул ук китаптагы «Нуры содур» поэмасының тәрҗемә тексты буенча кыскача күзәтү ясыйбыз.

Аллага дога, пәйгамбәр һәм сәхабәләргә, хәлифләргә мәдхия җырлаганның соңында Мөхәммәдъяр Казан (1521- 1524) һәм Кырым (1532-1551) ханы булып торган Сахиб Гәрәй ханны мактауга күчә. Сахиб Гәрәй хан чыннан да бик мәдәниятле, тирән фикерле, укымышлы кеше була. Аның кылган эшләре дә (Кырымда ясаган реформалары, сарайлар, мәдрәсәләр төзетүе һ.б.) аның үз вакытының алдынгы кешесе булуын күрсәтеп торганнар. Автор алладан аңа озын гомер бирүен сорый, аның исәнлегенә догалар кыла.

Һәм:

«Гаделлек белән, шаһ, чыкты атыгыз,
Дөньяда һәрвакыт булсын затыгыз» —ди.

Гаделлек турында шагыйрь байтак язган. Алланың гаделлеге ту-

рында да, патшаларның хәер-һаһлыгы буенча да күп мисаллар китереп, ул болай, ди:

Тыңла: әгәр патша кылса гаделлек,
Гаделлектән халык тапса ireклек,
Һәр кемгә дә тияр аннан зур өлеш—
Барча халык рәхәтләнер бу килеш.
Гадел белән генә булыр ил әман,
Калмас илдә золым һәм фетнә һаман.

Бу теманы дәвам итеп, автор Көнчыгыш әдәбиятында гаделлеге белән дан казанган Иран шаһиншаһы Ануширванның (531- 579) вәзирләре белән әңгәмәсен дә тасвирлый. Алга китеп ул юмартлык турында җырлый.

Юмартлык бар гаепләрне бетерер,
Юмартка ул әҗерен дә китерер.

Бер фәкыйрь егет таудан утын ташып көн күрә торган булган. Бер вакыт юлда берәүнең икенче берәүне кыйнавын күргәч, ни өчен сине кыйныйлар, дип сораган: тегеннән ике тәңкә акча бирәсем бар иде, акчам юк, дигән җавапны алган. Үзенең көнлек керемен, ике тәнкә акчасын биреп, ул аны коткарган. Икенче көнне ул балык сатучыны күрә, балыгын алучы юк, искергән диләр. Аны бәладан коткарам дип, утынын аңа бирә, егет өенә балык алып кайта. Балыкның эчен ярып чистарта башлыйлар, ә аннан йөз мең тәңкәлек энҗе килеп чыга. Юмартлыкның бәһасы кайта. Балык эченнән асылташ табылу, шул сәбәпле ярлының баеп китү сюжеты күп халыкларда киң таралган тема. Мөхәммәдъяр аны берничә урында файдаланган. Дүртенче бүлек оялчан һәм тыйнак булу кирәклеге турында сөйли.

Кем эчендә саклый алса оятын,
Изгелек белән чыгарыр ул атын.
Димәк, оятсыз кешедә иман юк,
Оятсызлык - авыру ул, дәвасы юк.
Тик оятсыз кешедән килер яман,
Һич оялмас, китерер илгә зыян.

Тыйнак булу хакында да шундый фикерләр әйтелә. Бер гарәп патшасы үзен алдаучыны да җәзага тартмаган, тозлы суын калдыртып, үзен җибәргән. Газават һәм газилар турындагы шигырьләр батырлык, курыкмаучылык турында сөйли, ләкин сугышырга чакырмый. Шуңа бәйле рәвештә булса кирәк, сәяхәтче бер егет шәһитләр сараена юлыга,

Хөзер— Ильясны, кеше кыяфәтендәге Җәбраилне күрә, алар аңа хак юлны күрсәтә. Автор бик матур итеп сабыр булырга чакырып та яза.

Сабыр белән барча эш хасыйл булыр,
Сабыр кылган һәрвакыт гакыйль булыр.

Ягъкуп картның ничә еллар буена улы Йосыфны күрү өмете белән яшәп сабыр итүе мисалында, ул кешеләрне сабырлыкка чакыра:

Барча эштә сабыр бул син, хөрмәтле,
Сабыр сүзен аңла, гаклы сәләтле.

Сабырлыкка тагын бер мисал итеп патшасы каршысында утырган бер вәзирнең тәнендә чаян йөрсә дә, аны чаккаласа да, ул түзеп, сабыр булып утыра биргән, патшаны бүлдермичә тыңлаган һәм патшаның бүләкләвенә лаек булганы турында хикәят итеп сөйләнә. Менә тагын тугрылык, сүздә торулык хакында шигырьләр:

Хөрмәтле булырга теләсә кеше,
Сүздә даим тугрылык булсын эше.
Биргән вәгъдәсендә булсын ул вафа,
Булмый икән, үлгәчтән күрер җәфа.

Турылык (вафа), дөрес сүзле булу турында өндәп, шагыйрь болай яза:

Дөреслектән бәхет табар барысы,
Чын сүз итәр кечене ил олысы.
Ялган булса тел, бары ялган килер,
Шул сәбәпле абруе түгелер.
Котылмастыр кеше ялган сүз белән,
Даим тормыш табар тугры сүз белән.

Телен тыймыйча, юк-барны сөйләп йөрүчеләргә, гайбәтчеләргә шагыйрь бик каты һәм дөрес бәрелә:

«Телен тыйган һәркем котыла ул,
Телен тыймаган һәрчак тотыла ул».

Аз сүзле булуны, дәшми калуны автор хуплый. Берничә урында югарыда күрсәтелгән яхшы сыйфатлар нәтиҗәсендә (юмартлык, сабыр булу, дәшми калу кебек) аерым кешеләрнең, яһүдләрнең дә ислам диненә чыгуларын әйтә.

Озын гына итеп автор бер берәңне гафу итә белергә дә өнди. Ике патша дошман булып сугышка чыгалар. Бер әсир егет җиңүче шаһтан матур сүзләр белән гафу ителүне сорый. Миһербанлы шаһ әсирләрнең барысында гафу итеп азат итә.

Аллаһы Тәгалә дә Заһид белән сөйләшеп аның гөнаһларын гафу итә, чөнки Заһид гомере буе аллага гыйбадәт кыла. Ләкин соңрак ул бик сусый, су бирегез,дип ялвара. Бер фәрештә килеп, кылган гыйбадәтләреңне миңа бирсәң, су бирәм, ди. Ахыр чиктә Заһид риза була, ә Аллаһы Тәгалә изгелегеңне бер чәшкә суга саттың, кер тамугка, ди. Заһид тагын ялвара, гафу итүне сорый, синең күңелең бик киң, дип аны мактый. Алланың чыннан да күңеле киң рәхмәтле икән, ул аны тагын гафу итә:

«Бар да кер хәзер җәннәтнең үзенә,
Хур кызын да багышладым үзеңә».

Шагыйрь кешене кеше булганлыгы өчен бик югары куя. Аңа гаҗәп матур теләкләр теләп догалар укый. «Нуры содур» поэмасы Мөхәммәдъярның барлык иҗаты кебек үк нәсихәтләр әсәре.

Поэманың язылу вакытын һәм урынын шагыйрь үзе болай билгеләгән:

Тарих тугыз йөз кырык сигезендә,
Бәхетле мөхәррәм ун икесендә,
Болгар шәһәре Казанның капкасында,
Хәйран калган күп кеше капкасында.
Мөхәммәт Әмин кабрендә, и шәһрияр,
Мөҗавир буламын, татып бик күп зар.

Казанның болгар иле шәһәре булганлыгы билгеле. Мөхәммәт Әмин хакында югарыда әйтелде. Аның кабере янында күзәтүче булып шагыйрьнең яшәве гаҗәп хәл түгел, андый хәлләр төрки дөньяда элек тә, соңрак та булган. Һиҗри 948 нче ел, мөхәррәм аеның 12 нче көне - миляди ягъни хәзергечә 1541 нче кәбисә ел май аеның 12 сенә якшәмбе көненә туры килә. Әсәргә күзәтү югарыда кулланылган «Мөхәммәдъяр. Нуры содур» китабыннан алынып эшләнде.

Казан дәүләтенең руханилар башлыгы Кол Шәриф сәед кенә булып тормаган, бәлки дәүләт эшлеклесе дә, шагыйрь да булган. Ул тирән белемле, дин галиме булу белән бергә, дөнья хәлләрен зирәк күрә алуы, фәлсәфәи карашлары белән дә аерылып торган. Менә аның дөньяга фәлсәфи карашыннан бер мисал:

Әүвәлене кемсә белмәс, ахырыны һәм шулай,
Әүвәле һич, ахыры һич, бер борынгы дөньядыр.
Кол Шәриф, атаң- анаң, сәндин борынгылар кайда,
Барчаны куенына әшнә кыйлган дөньядыр.

Бу сүзләр вакытның һәм галәмнең иксез- чиксезлеген аңлата булса кирәк.

Кол Шәриф сәед, билгеле булганча, Казанны урысларга бирмәс өчен сугышып 1552 елның 2 нче (хәзергечә 15 нче) октябрендә шәһит булган. Аның рухы хөрмәтенә мәчет торгызу татар халкы өчен шатлыклы күренеш.

Ул заманнардан калган башка әсәрләргә тукталмыйча, укучыларга рәхмәт әйтеп, язуымны шуның белән тәмамларга булдым.

# ЭЧТӘЛЕК

**1. Документаль чыганаклар** ..................................................... 3
Казан ханнары ярлыклары ..................................................... 3
Искәрмәләр ..................................................... 23
**2. Эпиграфик чыганаклар** ..................................................... 25
Кабер ташы язмалары ..................................................... 25
Шәҗәрәләр ..................................................... 33
Файдаланылган хезмәтләр. ..................................................... 38
**3. Халык авыз иҗаты** ..................................................... 39
**4. Матур әдәбият әсәрләре** ..................................................... 53

*Алишев С.Х.*

**Казан ханлыгы чорындагы татарча чыганаклар**
(на татарском языке)

*Научное издание*

Оригинал макет – *Л.М.Зигангареева*
Отпечатано в множительном центре
Института истории АН РТ
Заказ № 019 Тираж 500 экз.
Усл.печ.л. 4,5 Сдано в набор 25.12.2002 г.
г.Казань, ул. Кремлевская, 10/15
тел. 92-91-04, 92-84-82